«Зарница җитештерү берләшмәсе» оешмасын тикшерү барышында хезмәткәргә эштән азат ителгәндә тиешле барлык сумманы түләмәү, хезмәт килешүен өзүдән баш тарту кебек хезмәткәрнең хезмәткә хокукларын бозу фактлары ачыкланды.

Тулаем алганда, республикада, дәүләт Статистика федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы территориаль органы мәгълүматлары буенча, хисап биргән авыл хуҗалыгы, ау һәм агач әзерләү, эшкәртү, төзелеш тармагы предприятиеләре һәм оешмаларында хезмәт хакы буенча кичектерелгән бурыч 2019 елның 1 гыйнварына 99,022 миллион сум тәшкил иткән. Кызганычка каршы, әлеге күрсәткеч узган ел белән чагыштырганда күп тапкырга артты (2018 елның 1 гыйнварына бурыч 10,574 миллион сум тәшкил итте).

Әлеге вәзгыять шактый дәрәҗәдә аерым предприятиеләр аркасында килеп чыкты. Мәсәлән, «Татфлот» суднолар компаниясе» һәм аның филиалларында хезмәт хакы буенча гомуми бурыч 96 358 мең сум тәшкил итте, ә 2018 елның апреленнән бәйге производствосы ачылган «Спартак»аяк киеме» ширкәтендә бурыч 986 мең сум тәшкил итте.

Хезмәт хакын үзвакытында һәм тулысынча алуга хезмәт хокукларын суд аша яклау ысулы татарстанлылар өчен иң киң таралган ысулларның берсе булып тора. Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе мәгълүматларын анализлау шуны күрсәтә, кызганычка каршы 2007 елның 2 октябрендә дөнья

күргән 229-ФЗ нче «Башкару производствосы турында» (бурычлының һәм аның милкенең кайдалыгын белмәү, түләү алу өчен милек булмау) федераль законда күрсәтелгән төп нигезләр буенча акча алалмау турындагы акт белән тәмамланучы башкару эшләре арта. 2018 ел йомгаклары буенча ул 6,1 процент тәшкил итте (2017 елда – 4,6 процент, 2016 елда – 1,9 процент).

Башка сүзләр белән әйткәндә, узган ел йомгаклары буенча суд карарыннан соң һәм аларга карата кузгатылган башкару производствосы буенча хезмәт хакы буенча бурычын түләгән 100 эш бирүчегә суд приставлары-башкаручылары эзләп табалмаган яки түләүгә сәләтсез булган 6 эш бирүче туры килгән. 2017 елда хезмәткәрләренә акча түләгән 100 эш бирүчегә «проблемалы» эш бирүчеләр саны 4-5, ә 2016 елда нибары 2 тәшкил итте. Шул ук вакытта хезмәт хакы алу буенча бурычларны кайтару турында башкару документлары буенча төгәлләнгән башкару эшләренең гомуми саны кимүгә карамастан, (2018 елда төрле нигезләр буенча 3743 башкару производствосы, 2017 елда биш меңнән артык башкару производствосы, 2016 елда сигез меңнән артык башкару производствосы) башкару производствосы алу мөмкин булмау турында акт белән тәмамланган башкару производствосы очраклары саны 2017 ел белән чагыштырганда абсолют күрсәткечләрдә сизелерлек артты. 2018 елда андый очраклар 194 булса, 2017 елда - 143 кенә иде.

Шулай итеп, иминият һәм башка мәҗбүри взнослар буенча «проблемалы» предприятиеләр хуҗалык эшчәнлеген территориаль ведомствоара комиссияләрдә анализлау буенча җентекле эш кирәклеге ачыкланды.

Эшсезлек дәрәҗәсе түбән булу халыкның яхшы яшәвенең бер күрсәткече.

«2014-2021 елларга Татарстан Республикасы халкы мәшгульлегенә булышлык итү» дәүләт программасын тормышка ашыру барышында, халыкны эшле итү чараларын тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан 2018 елда 1 382 482 сум сум акча каралган, 2014 елдан 2018 елга кадәр эшсез дип танылган гражданнар саны Татарстан Республикасында ике тапкыр – 23267 дән 10277 гә кадәр кимеде. Республикада эшсезлек дәрәҗәсе дә илдәге уртача

күрсәткечтән ике тапкыр диярлек түбән (республикада 0,5 процент, Россия Федерациясендә 0,9 процент).

2018 елда «Демография» милли проектын тормышка ашыру кысаларында гаилә институтын яклау эше дәвам иттерелде. Өч яшькәчә яшьтәге балалары булган хатын-кызларны яңа һөнәргә өйрәтү өчен шартлар тудырылды. 2012 елдан башлап өч яшькәчә баласы булган 6,2 мең хатын-кыз өйрәтелде. 2019 елда бала карап өйдә утыручы тагын 600 хатын-кызны өйрәтү күздә тотыла.

Республикада эшсезлек аз булуга, нәтиҗәле хезмәт базарын үстерүгә, эшче көчкә сорау һәм ихтыяҗның структурага ярашмавын җиңүгә, легаль булмаган мәшгульлек өлешен киметүгә карамастан, эш эзләгәндә авырлыклар кичерү затларның хезмәткә хокукларын яклауның аерым мәсьәләләре игътибарны җәлеп итәләр.

2018 елда республика җитәкчелеге хәрби хезмәткә алынган егетләрнең эш урыннарын саклау бурычын куйды. Асылда Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә эш урыннарын саклау буенча чаралар күрелү меңнәрчә татарстанлыга кагылды.

Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты мәгълүматы буенча 2018 елда гаскәрләргә 6663 татарстанлы чакырылган. Шулардан 260 кеше дәүләт предприятиеләрендә һәм учреждениеләрендә эшләгән (1998 елның 27 маенда дөнья күргән 76-ФЗ нче «Хәрби хезмәткәр статусы турында» федераль законның 23 маддәсенә ярашлы рәвештә эш урыннарын саклау хокукы каралган) һәм 1058 е башка төр предприятиеләрдә эшләгән, чакырылыш буенча хәрби хезмәттән запаска киткәннән соң аларга эш урыннарын саклау каралмаган.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Профсоюзлар федерациясе, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, Татарстан Республикасы эш бирүчеләре берләшмәләре Советы арасында төзелгән 2019-2020 елларга социаль-икътисадый сәясәт үткәрү һәм социаль партнерлыкны үстерү турында республика килешүенә өстәмәләр кертелде. Аларга ярашлы рәвештә, профсоюзлар килешүләр һәм күмәк килешүләр аша хәрби хезмәткә чакырылу яисә аны алыштыручы альтернатив хезмәткә җибәрелү аркасында хезмәт килешүләре тукталган, элеккеге эш бирүчегә мөрәҗәгать иткән гражданнарга эшкә урнашырга булышырга тиеш.

Эш бирүчеләр өчен килешүдә социаль ярдәмгә аеруча мохтаҗ булган, эш эзләүдә авырлык кичергән гражданнарны эшкә урнаштыру йөкләмәләре, шулай ук хәрби хезмәттән яки аны алыштыручы альтернатив гражданлык хезмәттән киткәч өч ай эчендә, хәрби хезмәттән яки аны алыштыручы альтернатив хезмәткә чакырылу аркасында хезмәт килешүләре туктатылган элеккеге эш бирүчесенә мөрәҗәгать иткән гражданнарны эшкә алуга булышлык итү йөкләмәләре күрсәтелгән.

2019 елда һәм аннан алдагы елларда республика килешүенең әлеге положениеләрен тормышка ашыру мөһим дип саныйбыз.

Агымдагы елның 1 гыйнварыннан пенсия яшен этаплап күтәрү башланды. Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматларына ярашлы рәвештә, киләсе елда пенсия реформасына 55 меңгә якын кеше эләгә. 2018 елда мәшгульлек органнарына пенсия алды яшендәге меңгә якын эшсез кеше мөрәҗәгать итсә, киләсе елда аларның саны өч меңгә кадәр артачак. Республиканың дәүләт органнары тарафыннан 9,1 мең оешмада эшләүче 24,3 мең пенсия алды яшендәге кеше мониторингы буенча эш башланды.

Бу уңайдан 2019 елдан «Демография» милли проектының «Өлкән буын» проекты кысаларында пенсия алды яшендәге кешеләрне һөнәргә өйрәтүне оештыру күздә тотыла, аның кысаларында 1351 кеше өйрәнүгә җибәреләчәк.

Шуның белән бергә, дәүләт органнары эше пенсия алды яшендәге кешеләрне өйрәтүгә һәм хезмәт хокукларын саклау ысуллары турында халыкка мәгълүмат бирүгә генә түгел, ә халык мәшгульлеге өлкәсендә дискриминациягә юл куючы эш бирүчеләргә карата кисәтү чаралары системасын куллануга юнәлтелергә тиеш.

Интернет челтәрендә job.upper.ru, rjb.ru, trudvsem.ru, kazan.trud.com кебек сайтларны күзәтү барышында без «менеджерлар», «инженерлар», «администраторлар», «ПК операторлары», «сәркатипләр», «автотранспорт диспетчерлары» вакансияләре турында мәгълүматлар урнаштырганда, яшькә кагылышлылары булуга да игътибар иттек. Әлеге очракларда эш бирүчеләр тарафыннан яшь чиге куелган иде – 45 яки 55 яшькә кадәр. Шундый белдерүләрнең берсе «Әлмәт шәһәре мәшгульлек үзәге»ндә урнаштырылган иде.

Бу уңайдан Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгына һәм мәшгульлек хезмәте органнарына яшь буенча эшкә алган вакытта дискриминацияне кисәтү буенча тиешле чаралар кабул итәргә кирәк.

Халыкның мәшгульлеге һәм хезмәт хакын үзвакытында һәм тулысынча түләүне тәэмин итү белән беррәттән, хезмәт куркынычсызлыгы шартлары халыкның яхшы тормышының аерылгысыз билгесе булып тора.

Тулаем алганда республикада производствода бәхетсезлек очраклары санын киметү буенча эш дәвам иттерелде, шул исәптән хезмәтне саклау һәм шартларын яхшырту программасын тормышка ашыруга ел саен бюджеттан 5 миллион сум акча бүлеп бирү юлы белән.

Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматлары буенча биш елда үлем-китем белән производствода зыян күрүчеләр саны 2,1 процентка кимеде (2014 елда – 60 һәлак булучы булса, 2018 елның 1 декабренә – 28 кеше). 2018 елда үлем-китем белән производствода зыян күрүчеләр саны 2017 ел белән чагыштырганда (44 һәлак булучы) 30 процентка кимеде.

Шунысын да билгеләргә кирәк, үлемгә китергән бәхетсезлек очраклары саны кимүгә административ тәэсир итү чаралары яисә гаепле вазифадагы затларны җинаять җаваплылыгына тарту чаралары кабул итү белән генә түгел, хезмәткәрләрне һәм эш бирүчеләрне хезмәтне саклау таләпләренә өйрәтү буенча максатчан эш, предпрятиеләрендәге эш урыннарында хезмәт шартларына махсус бәя үткәрү сәбәпче.

2018 елда республикада хезмәтне саклау таләпләренә 45,2 кеше өйрәтелде. Хезмәт шартларына махсус бәя үткәрелгән эш урыннары саны 48,2 процентка артты (2018 елның 1 гыйнварында 340 700 урыннан 2018 елның 1 ноябренә 504 927 урын).

Муниципалитетлар каршында төзелгән һәм хезмәткәрләрнең производствода саулыкларын саклауга юнәлтелгән, хезмәтне саклауның мөһим мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр эшләүгә юнәлтелгән муниципаль районнардагы һәм шәһәр округларындагы хезмәтне саклау буенча координацион советлар эшенә шактый игътибар бирелә.

Шуның белән бергә, Татарстан Республикасы дәүләт Хезмәт инспекциясе 2018 елда производствода авыр һәм үлем очраклары турында биргән мәгълүматта, 34 бәхетсезлек очрагының дәүләт һәм муниципаль оешмалары һәм предприятиеләрендә килеп чыгуы фактлары сагайта. Кеше саны зур булмаган – Арча һәм Теләче районнарында муниципаль районнарның башкарма комитетлары буйсынуындагы учреждениеләрдә сәламәтлеккә авыр зыян салу яисә үлемгә китергән ике бәхетсезлек очрагы булды.

Арча һәм Теләче муниципаль районнары башкарма комитетларына алар буйсынуындагы учреждениеләрдә хезмәтне саклау өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне ныклы үтәүгә юнәлтелгән чаралар күрергә кирәк.

Моннан тыш, 2018 елда производствода иң күп бәхетсезлек очраклары Казан, Чаллы шәһәрләрендә, Түбән Кама, Әлмәт, Яшел Үзән муниципаль районнарында булды. Иң киң таралган очраклар – хезмәткәрләрнең биектән егылуы һәм детальләр белән җәрәхәтләнүе.

Хезмәт законнары һәм хезмәтне саклау өлкәсендә мөсьәләләрнең социаль әһәмиятен исәпкә алып, Вәкаләтле вәкил Аппараты Татарстан Республикасында дәүләт Хезмәт инспекциясе, Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Профсоюзлар федерациясе республиканың муниципаль районнарында һәм шәһәр округларында (Мамадыш, Менделеев, Чистай районнарында һәм Чаллы шәһәрендә) гражданнарның хезмәткә хокукларын саклау мәсьәләләре буенча эш бирүчеләр өчен тематик семинар-киңәшмәләр оештырды.

Семинарлар предприятиеләр һәм оешмалар җитәкчеләре, хезмәтне саклау буенча хезмәтләр белгечләре, җирле үзидарәләр органнары вәкилләре, профсоюз оешмалары рәисләре өчен практик мәйданчыклар булды. Әлеге семинарларда 200 эш бирүче һәм кадрлар һәм хисапчылар хезмәтләре хезмәткәрләре булды. Шул уңайдан хезмәт законнарындагы яңалыклар турында эш бирүчеләрне хокукый агартуны оештыру ягыннан эшне дәвам итәргә уйлыйбыз.

Хезмәт - һәр кешенең байлык чыганагы булып тора. Шул ук вакытта хезмәт - дәүләт һәм җәмгыятьнең социаль үсеше нигезе. Шушы уңайдан кешенең хезмәткә хокукларын саклау

эш бирүчеләрнең хезмәт законнарын үтәвенә контрольлек һәм күзәтчелек нәтиҗәлелеген күтәрү кирәклеген күздә тота. Контроль превентив булырга тиеш, бигрәк тә гражданнарның хезмәткә хокукларын бозуга күп тапкырлар юл куйган эш бирүчеләргә карата.

## Гражданнарның торакка хокукларын саклау

Россия Федерациясе Конституциясе положениеләренә ярашлы рәвештә дәүләт хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары торак төзелешен хуплыйлар, торакка хокукны тормышка ашыру өчен шартлар тудыралар. Татарстан Республикасында элеккечә үк югары төзелеш темплары саклана. 2018 елның гыйнварыннан ноябренә кадәр республикада 2088086 квадрат метр торак сафка бастырылды, бу 2017 елның шул чорына караганда 1,1 процентка күбрәк (ул чорда - 2065576 квадрат метр). Гомумән алганда, 19718 фатир һәм 7887 шәхси йорт төзелә.

Үткән елда Татарстан Республикасында 297 ятим бала, 69 яшь гаилә, 31 Бөек Ватан сугышы ветераны, 46 күп балалы гаилә торак белән тәэмин ителгән. Социаль ипотека программасы кысаларында 438 мең квадрат метр торак кулланышка тапшырылган. 967 күпфатирлы йортларда капиталь ремонт үткәрелгән.

Ел нәтиҗәләре буенча 5 проблемалы өлешләп төзү объекты тапшырылган, 517 өлешләп төзетүче кеше яңа фатирлы булган. Шуның белән бергә, кызганычка каршы, «алданган өлешчеләр» проблемасы ахырына кадәр хәл ителеп бетмәгән.

2018 елда гражданнарның торак шартларын яхшыртуны һәм тиешле торак һәм коммуналь хезмәтләре алуны тормышка ашырырга юнәлтелгән булган норматив хокукый актларга берничә өстәмәләр һәм норматив хокукый актлар кабул ителде. Алар арасында түбәндәгеләрне күрсәтергә була.

Федераль дәрәҗәдә төзүчеләр һәм өлешләп төзетүчеләр арасында мөнәсәбәтләрне көйләү максатыннан, намуссыз төзүчеләрдән зыян күргән затларны яклау өчен төбәк фондлары булдыру мөмкинлеге беркетелде. 2018 елның 9 мартында Татарстан Республикасы Президенты указы белән намуссыз төзүчеләрдән зыян күргән затларны яклаучы республика фонды төзелде.

2018 елның 3 апрелендә закон чыгаручы милекчеләргә һәм күпфатирлы йортлардагы милектән вакытлыча файдаланучыларга каты коммуналь калдыклар җыючы төбәк операторлары һәм ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар белән турыдан туры килешүләр төзү мөмкинлеге бирде.

Үз чиратында гражданнарның торакка хокукларын саклау белән бәйле мөрәҗәгатьләр Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә килгән мөрәҗәгатьләр арасында күпчелекне тәшкил итә.

2018 ел дәвамында Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына гражданнардан социаль найм килешүләре төзегәндә, торак биналарын яшәргә яраксыз дип тану процедурасында законсыз кире кагулар белдергән, торак йортлардагы терәк конструкцияләр ишелү сәбәпләрен бетерү буенча чаралар күрмәгән җирле үзидарә органнарыннан зарланган шикаятьләр килде.

Вәкаләтле вәкил адресына килгән мөрәҗәгатьләрдән, гражданнарның аларны аварияле торак фондыннан күчерүләре белән килешмәү турындагы, шул исәптән торак биналарын яшәргә яраксыз дип һәм күпфатирлы йортларны аварияле итеп тану тәртибеннән, йортларны аварияле дип таныргa тиешле ведомствоара комиссияләр эшеннән канәгать булмаган шикаятьләрен аерып күрсәтергә була.

Гражданнарның бу тема буенча мөрәҗәгатьләрен караудан тыш, Вәкаләтле вәкил районнарның ведомствоара комиссияләр эшчәнлеге турында норматив-хокукый актларга анализ ясады. Анда Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварында дөнья күргән 47 нче «Торак бинасын яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны аварияле дип тану һәм сүтү яки төзекләндерү турында Положениене раслау турында» карары таләпләрен бозу очраклары ачыкланды.

Кайбер районнарда (Түбән Кама, Баулы, Саба) ведомствоара комиссия составына янгын, экология һәм башка куркынычсызлык өлкәләреннән дәүләт контроле һәм күзәтчелеге органнары вәкилләре кертелмәгән. Мөслим, Чирмешән районнарында санитар-эпидемиология куркынычсызлыгы, кулланучылар хокукларын саклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеге органнары вәкилләре читтә калган.

Шулай итеп, ведомствоара комиссияләр составлары тулы булмаган һәм һәр тикшерү очрагында, шул исәптән физик затлардан кергән гаризалар буенча, торак биналарын яшәргә яраклы яки яраксыз дип тануга бәя биргәндә объективлыкка булышлык итмәгән.

Мәсәлән, Вәкаләтле вәкил адресына торак бинасын яшәргә яраксыз дип тану турында Баулы шәһәрендә яшәүче мөрәҗәгать итте. Баулы районы ведомствоара комиссиясе составы тулы булмаса да, җирле үзидарә органы гариза бирүченең торагын яшәү өчен яраклы дип таба.

Яңа Чишмә һәм Кайбыч муниципаль районнарында ведомствоара комиссия эшенә киңәшләшү хокукы белән торак йорт милекчесе җәлеп ителмәгән. Шулай итеп, кешеләр торакны яшәү өчен яраклы яки яраксыз дип тану буенча комиссия эшендә катнашудан мәхрүм калганнар.

Хокук бозуларның барлык очракларында Вәкаләтле вәкил муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарына булган хокук бозуларны бетерүне сораган заключениеләр җибәрде.

Шуның белән бергә, бу мәсьәлә буенча гражданнарның торакка хокукларын саклау гарантиясен Вәкаләтле вәкил тикшереп кенә хәл итә алмый. Башкарма комитетлар җитәкчеләре ведомствоара комиссияләр эшенә аеруча игътибарлы булырга тиеш. Торак йортларның тиешле таләпләргә ярашлыгына бәя бирү процедурасының дөреслеге һәм тулы булуы актуальлеге, 2019 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 1 гыйнварына кадәр эшләргә тиешле Торак-коммуналь хуҗалыгы реформасына булышлык итү фонды эшчәнлегенә кагылышлы Россия Федерациясе хөкүмәте билгеләгән «Торак-коммуналь хуҗалыгы реформасына булышлык итү фонды турында» федераль законга үзгәрешләр кертү турында»гы федераль закон кабул итүгә нигезләнә.

Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварында дөнья күргән 47 нче «Торак бинасын яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны аварияле дип тану һәм сүтү яки төзекләндерү турында Положениене раслау турында» карары белән торак бинасы җавап бирергә тиешле таләпләр билгеләнгән. Шундый таләпләрнең берсе – тавыш, вибрациянең тиешле дәрәҗәсе.

2018 елда кергән шикаятьләр уңаеннан, чыганагы - транспорт хәрәкәте интенсивлыгыннан тавыш арту һәм әйләнә-тирәдә башка факторлар булу аркасында яшәү шартларыннан канәгатьсезлек белән бәйле хәл игътибарны җәлеп итте.

Вәкаләтле вәкил адресына Казан шәһәренең Җиңү Проспекты буендагы автомагистральгә якын йортларда яшәүчеләр, автотранспорт күп булганлыктан тавыш булудан мөрәҗәгать итте. Тавыш дәрәҗәсен үлчәү буенча үткәрелгән тикшерүләр фактларны раслады, Роспотребнадзорның Татарстан Республикасындагы идарәсе Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетына тавыш дәрәҗәсен санитар нормалар һәм кагыйдәләр белән каралган күрсәткечләргә җиткерү буенча чаралар күрү өчен хат җибәрде.

Асылда йортларда яшәүчеләрнең имин һәм зыянсыз яшәү шартларын тәэмин итү турындагы мәсьәлә шәһәр бюджетында тавыш кайтаргыч экраннар төзүгә кирәкле акча булмау сәбәпле хәл ителмәде.

Моңа охшаш хәлләрне Роспотребнадзорның Татарстан Республикасындагы идарәсе Казан шәһәренең Энергетиклар урамындагы 4 нче йорт янында (трамвайлар күп йөри) һәм Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында (торак йорт янында машиналар хәрәкәте күп) ачыклады.

Суд практикасында, Россия Федерациясенең төрле төбәкләрендә җирле үзидарәләр органнарына тавышның тиешле дәрәҗәдән артып китүен бетерү турындагы дәгъва гаризалары җәмәгатьчелек транспорты тукталышын сүтү, шулай ук торак йорт тирәли тавыш кайтаргыч корылмалар кую һәм башка чаралар белән канәгатьләндерелгән. Җирле үзидарә органнары, йортларда яшәүчеләр мондый очракларда уңайлы яшәү шартлары тудыру буенча мөстәкыйль чаралар кабул итә алмаганлыктан, бу мәсьәләне хәл итәргә тиеш.

Вәкаләтле вәкил адресына торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсендә оешмалар эшенә шикаятьләр килү дәвам итә.

Идарәче компанияләрнең агымдагы ремонт үткәрү буенча эшләмәве, торак йортларга җылы бирү буенча торак-коммуналь хезмәтләрнең тиешенчә күрсәтелмәве, идарәче оешмаларның үз эшчәнлеге турындагы мәгълүматын ачып җиткермәве, коммуналь хезмәтләр өчен төрлечә исәп-хисап ясаулары, идарәче оешмаларның

яңа милекчеләрдән торак йортта элеккеге яшәүчеләрдән калган коммуналь хезмәтләр өчен бурычларны бетерүне таләп итүе мәсьәләләре татарстанлылар өчен актуаль булып кала.

Казан шәһәренең Парин урамының 16 нчы йортында яшәүчеләрдән идарәче компаниянең тиешенчә эшләмәве турында язылган шикаять моңа мисал була ала. Алар түбәне тиешенчә төзәтмәүләре аркасында су баскан фатирларга ремонт үткәрү турында Вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать итте. Компетентлы органнар белән бергә оештырылган контроль чаралар нәтиҗәләре буенча йортта яшәүчеләрнең хокуклары бозылу фактлары расланды һәм идарәче компания торак биналарын ремонтлау буенча тиешле чаралар күрде.

Мөрәҗәгатьләрне караудан тыш, торак-коммуналь хуҗалыгы проблемалары буенча Татарстан Республикасы «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына килгән мөрәҗәгатьләрне карау йомгаклары буенча аерым нәтиҗәләр ясарга була. 2018 елда «Торак-коммуналь хуҗалыгы» төре буенча системада 4447 шикаять бастырылды, шуларның 4167 се хәл ителде.

Күп кенә шикаятьләр турыдан-туры Вәкаләтле вәкилнең катнашканнан соң гына хәл ителде.

Кайбер очракларда җаваплы үтәүчеләр мөрәҗәгатьләр карау вакытын нигезсез суздылар. Мәсәлән, Чаллы шәһәренең торак йортындагы су агу торбасын ремонтлауга һәм подъезд кыегын буярга, керү ишеген алыштырырга тугыз ай таләп ителә, Яшел Үзән шәһәрендәге күпфатирлы йорт түбәсенең калаен алыштырганда килеп чыккан төзелеш кимчелекләрен бетерүгә - җиде ай, Казан шәһәренең бер йорты территориясендәге асфальтны яңартуга – унбер ай вакыт китә.

Кайбер шикаятьләр буенча идарәче оешмалар республикада яшәүчеләр проблемаларын хәл итү буенча йөкләмәләр кабул итмәделәр.

2018 елның 6 июнендә аварияле йорт дивары ишелү турында мөрәҗәгать кергәннән соң «Вахитов районы торак-коммуналь хуҗалыгы идарәче компания»се ширкәте белән башкарма комитет арасында озак вакыт аварияле йортны ремонтлау буенча чыгымнар сметасын әзерләүгә кагылышлы язышу бара. Вәкаләтле вәкил

катнашканчыга кадәр идарәче оешма йорт дивары ишелү куркынычын бетерү буенча бернинди практик чаралар күрмәде.

«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына 2017 елның 27 ноябрендә күпфатирлы йорт подвалын су басу турында килгән мөрәҗәгать буенча «Экономстрой+» ширкәте идарәче оешмасы без катнашканнан соң гына су басу сәбәпләрен ачыклап, аны бетерү буенча чаралар күрде.

Татарстан Республикасының «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына «Торак-коммуналь хуҗалыгы» төре буенча килгән мөрәҗәгатьләрне җаваплы үтәүчеләргә, аларны үтәү срокларына һәм сыйфатына ныклы игътибар бирергә кирәк дип саныйбыз.

Вәкаләтле вәкил практикасында торак-коммуналь хуҗалыгы мәсьәләләре буенча эшләүнең башка ысуллары да кулланыла. 2018 елның мартында тематик «кайнар элемтә» үткәрелде, анда бер көндә 64 кеше мөрәҗәгать итте.

«Татарстан Республикасында торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсендә җәмәгатьчелек контроле төбәк үзәге» коммерциячел булмаган партнерлыгы» һәм «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортлар белән идарә итү оешмалары берлеге» төбәк коммерциячел булмаган партнерлыгы» үзкөйләүле оешмасы белән берлектә, республика муниципаль районнарында (Алабуга, Менделеев, Алексеевский, Мамадыш) идарәче компанияләр вәкилләрен чакырып торак-коммуналь хуҗалыгы мәсьәләләре буенча халык өчен тематик «Хокукый ярдәм көннәре» үткәрелде. «Хокукый ярдәм көннәре»ндә торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсенә караган тематик лекцияләрне барлыгы 400 кеше тыңлады.

Гражданнарның торакка хокуклары, шулай ук тиешле торак-коммуналь хезмәт алуга хокукларына кагылышлы хәл торышы кешене социаль яклауның мөһим күрсәткечләре исәбенә керә. Әлеге хокукларны тормышка ашырмыйча һәр кешенең лаеклы тормышын һәм ирекле үсешен тәэмин итәргә мөмкин түгел.

## Сәламәтлек саклауга һәм медицина ярдәменә хокукларны саклау

Сәламәтлек – кеше өчен иң кадерле байлык, аннан башка күп кенә кыйммәтләр әһәмиятен югалтырга мөмкин.

Медицина ярдәме күрсәтү өлкәсендә үсешкә ирешү гражданнарга дәүләт гарантияләре федераль программасы буенча бушлай медицина ярдәме күрсәтү дәүләт гарантияләре төбәк программаларына ярашлыгын тәэмин итүгә ирешергә; медицина ярдәме күрсәтүгә бәяләрне арттыруга, авыруларны кисәтүгә, онкология ярдәмен үстерүгә, сирәк авырулар белән авыручыларны (аңа гемолитико-уремик синдром, үсмерләр башлангыч артриты, I, II һәм VI типтагы мукополисахаридоз кебек авырулар кертелгән) тәэмин итүгә билгеләнгән, тормыш өчен бик кирәкле һәм әһәмиятле дарулар исемлеген киңәйтүгә, шулай итеп, 200 мең кешене дарулар белән тәэмин итәргә мөмкинлек бирә. Ташламага ия гражданнарны дарулар белән тәэмин итүгә килгәндә, шуны билгеләргә кирәк, Вәкаләтле вәкил тарафыннан гражданнарны тагын да оперативрак тәэмин итүгә юнәлтелгән дару препаратлары дәүләт сатып алулары процедурасын камилләштерү мәсьәләсе күтәрелде. Әлеге тәкъдимнәрне Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил дә хуплады һәм алар Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Россия Федерациясе Финанслар министрлыгы каравына керде.

Кеше сәламәтлеге тормышка хокук белән өзлексез бәйләнгән. Гомер озынлыгын күтәрү – бу дәүләт бурычы. Россия Федерациясе хөкүмәте 2024 елга гомер озынлыгын 78 яшькә кадәр күтәрү бурычын куйды.

Кызганычка каршы, Татарстан Республикасында 2018 ел йомгаклары буенча, үлем күрсәткече артты һәм 44771 кешене тәшкил итте, бу 2017 елга караганда 1,7 процентка күбрәк, туу саны киресенчә, кимеде. 2018 ел йомгаклары буенча Татарстан Республикасында 46 792 сабый туган, бу 2017 елга караганда 3,7 процентка кимрәк, (ул елны 48 596 сабый туган).

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының туу саны кимү, үлүчеләр саны арту сәбәпләрен атап кына калмыйча, тискәре хәл сәбәпләрен бетерүгә юнәлтелгән чаралар кабул итүе дә мөһим.

Сәламәтлек саклауга һәм медицина ярдәменә хокукны саклау өчен халык өчен инфраструктура объектларының уңайлылыгын күтәрү мөһим. Бу максатларда республикада 2018 елда медицина оешмаларын (22 объект) матди-техник җиһазландыру буенча чаралар күрелде, 110 объект капиталь төзекләндерелде, авылларда өстәмә рәвештә 62 фельдшер-акушерлык пунктлары ачылды, бу үз чиратында бу мәсьәлә буенча шикаятьләрнең кимүенә китерде.

Үз чиратында, 2018 елда Вәкаләтле вәкил адресына мөрәҗәгатьләр шул исәптән, социаль челтәрләр аша да килде, күбрәк алар табибка язылу, табиб-белгечләрне көтү вакытын саклауга кагылышлы иде.

Татарстан Республикасы «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына «Сырхауханәләр һәм хастаханәләр» төре буенча килгән шикаятьләрне анализлау әлеге теманың татарстанлылар өчен актуаль булуын дәлилли.

Мәсәлән, «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына электрон рәвештә һәм башкача табибларга язылу мәсьәләләре буенча 2018 елда гражданнардан 633 (45%) шикаять килде, медицина хезмәтләре күрсәтү һәм аларны алу мөмкинлегенә (табиб кабул итүгә) кагылышлылары – 13 процент тәшкил итте, ягъни бу «Сырхауханәләр һәм хастаханәләр» төре буенча килгән гомуми мөрәҗәгатьләрнең яртысы.

Иң күп шикаятьләр Казан, Яр Чаллы шәһәрләреннән, Әлмәт һәм Түбән Кама муниципаль районнарыннан килде, (Казан шәһәре буенча – «8 нче шәһәр сырхауханәсе», «7 нче шәһәр клиник хастаханәсе», «6 нчы шәһәр балалар сырхауханәсе»; Әлмәт муниципаль районы буенча – «Перинаталь үзәк белән Әлмәт балалар шәһәр хастаханәсе»; Түбән Кама муниципаль районы буенча – «Түбән Кама үзәк район күп профильле хастаханәсе», «Перинаталь үзәк белән балалар шәһәр хастаханәсе».

Планлы язылу формасында күрсәтелә торган медицина ярдәмен көтү тиешледән арту белән бәйле табиб-белгечләргә язылу фактлары бер генә түгел, алар авыл районнарында гына түгел, дәүләт медицина оешмалары белән беррәттән, шәхси медицина клиникалары эшли торган эре шәһәрләрдә дә очрый.

Мәсәлән, граждан шикаятен тикшерү барышында шул ачыкланды, 2011 елның 21 ноябрендә дөнья күргән «Гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында»гы 323-ФЗ федераль законының 10 нчы маддәсен бозып, Чаллы шәһәренең «2 нче шәһәр хастаханәсе»ндә табиб-офтальмологның кабул итүен көтү вакыты 14 көннән артып киткән.

Казан шәһәренең «3 нче шәһәр сырхауханәсе»ндә гинекологка айдан артык язылу мөмкинлеге булмаган, «Түбән Кама үзәк район күпфункцияле хастаханәсе»нең сырхауханәсендә онкологка һәм офтальмологка, Казан шәһәренең «3 нче балалар шәһәр сырхауханәсе»ндә баланы невропатологка шулай ук айдан артык яздырып булмаган.

Медицина учреждениеләре мәгълүматларына караганда, табибларга язылып булмау мәсьәләсе буенча шикаятьләр саны арту кайбер учреждениеләрдә белгечләр җитмәүгә бәйле.

Мәсәлән, «6 нчы шәһәр балалар сырхауханәсе»ндә врач-офтальмолог урыны буш, шунлыктан төп табибка эш арткан. Казан шәһәренең «11 нче балалар шәһәр сырхауханәсе»ндә дә кадрларга кытлык – ортопед-травматолог, УЗИ-диагностика табибы юк.

Шуның белән бергә, Вәкаләтле вәкил фикеренчә, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы медицина оешмаларын кадрлар белән (мәшгульлек үзәкләре, медицина мәгариф учреждениеләре белән бергәләп) тәэмин итүгә контрольлек итәргә тиеш, кадрлар булмау гражданнарга медицина хезмәте күрсәтүне көтү вакытын арттыруга нигез була алмый.

Кабул итүгә язылу мәсьәләләре буенча шикаятьләрнең икенче сәбәбе - пациентларның табибларга керергә талон ала алмаулары.

Мәсәлән, Казан шәһәренең «21 нче шәһәр сырхауханәсе»ндә техник көйсезлекләр аркасында табиблар расписаниесе Бердәм дәүләт мәгълүмат системасында чагылыш тапмаган. «17 нче шәһәр сырхауханәсе» белән «2 нче клиник хастаханә» берләшү аркасында мәгълүмат базаларында өзеклек туган, Казан шәһәренең «7 нче шәһәр клиник хастаханәсе»ндә агымдагы айга квота булмау, «20 нче шәһәр сырхауханә»сендә табибларның авырып китүе, укуы аркасында кабул итүләр булмаган, Казан шәһәренең «4 нче балалар шәһәр

сырхауханә»сендә табиб-терапевт чираттагы ялда булу сәбәпле участок терапевтына язылырга, участок терапевты расписаниесен карарга мөмкин булмаган, кабул итү расписание урнаштырылмаган. Казан шәһәренең «8 нче шәһәр балалар сырхауханәсе»н үзгәртеп кору аркасында сырхауханәнең балалар бүлеге мәгълүматлар базасын «6 нчы балалар сырхауханәсе»нә тапшыру һәм берләштерү нәтиҗәсендә баланың электрон картасында хата килеп чыккан.

Вәкаләтле вәкилнең күчмә тикшерүләре вакытында Казан шәһәренең «6 нчы шәһәр балалар хастаханәсе»ндә прививка кабинетына чират торучы пациентларның күп булуы күренде. Физиотерапия процедуралары кабул итү һәм көндезге дәвалау стационарында дәвалану өчен пациентларга җәмәгать транспортының берсеннән икенчесенә күчеп утырып, икенче бинага барырга туры килгән, шул ук вакытта әлеге процедуралар өчен каралган кабинетлар тиешле максатларда файдаланылмаган, филиалларда ремонт эшләре сузылган.

Вәкаләтле вәкил катнашканнан соң, шулай ук «Татарстан Республикасы баш инвестицион-төзелеш идарә»се адресына җибәрелгән мөрәҗәгатьтән һәм медицина учреждениесе җитәкчелегенә һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына бирелгән тәкъдимнәрдән соң, икенче тапкыр барганда кимчелекләр бетерелгән: медицина учреждениесе филиалларында ремонт эшләре тәгәлләнгән, көндезге стационар һәм физиотерапия кабинетлары файдалануга тапшырылган, филиалда прививка ясату өчен өстәмә кабинет бирелеп, җиһазландырылган, бу прививка кабинетына чиратны киметкән иде.

Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм элемтә министрлыгына кабул итүгә язылуны камилләштерүгә кагылышлы тәкъдимнәрен җиткерде.

Болар - карау нәтиҗәләре буенча табиб-терапевт беренче тапкыр кабул иткәндә пациентны күрсәтмәләре буенча алга таба профиль табиб-белгечләрдә тикшертүне ачыклау очракларында «Табибтан табибка язылу» электрон язылу функционаллары; табибка язылуда актив язмаларны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль

хезмәтләре информеры аша, шулай ук «ТР хезмәтләре» мобиль кушымтасының «Сайланмалар» бүлегендә карау; кулланучыларга алдагы визит турында, кабул итүгә бәя бирүне сорап PUSH-хәбәрләр җибәрү.

Шул ук вакытта республикада табибка электрон рәвештә яки башкача язылуда, шул исәптән техник мөмкинлекләр булмау аркасында системалы проблемалар саклана. Шул исәптән, диспансер хисабында торган затлар өчен язылуда, кизү торучы табибка инфомат аша язылуда.

Шулай ук планлы профилактик прививка чаралар үткәрүгә кагылышлы шикаятьләр дә игътибарны җәлеп итә, бу иммунопрофилактика өлкәсендә дәүләт гарантияләрен киметә.

Мәсәлән, гражданнар медицина учреждениеләрендә вакциналар булмауга зарланды («Алабуга үзәк район хастаханәсе»ндә - «Превенар 13» вакцинасы, «Питрәч үзәк район хастаханәсе»ндә, Казан шәһәренең «7 нче балалар шәһәр клиник хастаханәсе»ндә – «Туберкулин» вакцинасы, Казан шәһәренең «11 нче балалар шәһәр сырхауханәсе»ндә - полиомиелит вакцинасы, Казан шәһәре «6 нчы балалар сырхауханәсе»ндә - пневмококк инфекциясеннән вакцина).

Мондый хәлләр тәэминатчыларда вакциналар булмау, җитмәгән препаратлар буенча медицина учреждениеләренең тәэминатчыларга үзвакытында өстәмә гаризалар бирмәве, шулай ук вакцинация буенча планны үтәүгә җитәрлек контроль булмау аркасында килеп чыга.

Гражданнарның сәламәтлек саклауга хокукларын бозуга юл куймау максатларында, Вәкаләтле вәкил фикеренчә, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы кызыксынган министрлыклар, ведомстволар һәм оешмалар белән берлектә табибка язылуны тәэмин итү, табиб-белгечләргә медицина ярдәме күрсәтү вакытыннан арттырмыйча, көтү вакытларына ярашлы рәвештә язылу, шул ук вакытта табиб-белгечләр консультацияләрен көтү вакытларын арттырмау, медицина оешмаларын иммунопрофилактика өчен иммунобиологик дару препаратлары белән тәэмин итү буенча чаралар күрүе, максатка ярашлы булыр иде.

## Белемгә хокукларны саклау

Россия Федерациясе Конституциясенә ярашлы рәвештә һәркемнең белемгә хокукы бар, ул дәүләт һәм муниципаль мәгариф учреждениеләрендә һәм предпрятиеләрендә бушлай мәктәпкәчә яшьтәге, төп гомуми һәм урта һөнәри белем алуны гарантияли.

Татарстан Республикасында 220284 сабый тәрбияләнүче 2020 мәктәпкәчә мәгариф оешмасы, 403132 укучы белем алучы 1413 гомуми белем бирү оешмасы, 149 732 студент укый торган 45 югары белем бирүче оешма, 68817 студент белем ала торган 91 һөнәри белем оешмасы бар.

2018 елда республикада 12 гомум белем бирү мәктәбе, 8 мәктәпкәчә мәгариф оешмасы төзелде, 122 мәгариф объектына капиталь ремонт үткәрелде (28 мәктәп, 94 балалар бакчасы), 3,5 миллиард сумлык 6 Россия Федерациясе дәүләт программасы тормышка ашырылды.

Шуның белән бергә, гражданнарның белемгә хокукларын тормышка ашыру өлкәсендә хәл итүне таләп итүче аерым проблемалар бар.

Вәкаләтле вәкил адресына гражданнардан белемгә хокуклары бозылу турында даими килеп торучы шикаятьләр әлеге проблемалар турындагы мәгълүмат чыганакларының берсе. Әлеге тема буенча мөрәҗәгатьләр Россия Федерациясе субъектларындагы Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр адресына да килә. Гражданнарның белемгә хокукларын яклау мәсьәләләренең актуальлеге һәм аларны яклау механизмнарын һәм ысулларын камилләштерү буенча эшләр тәкъдимнәрен эшләү максатыннан, алар 2018 елның ноябрендә Мәскәү шәһәрендә узган Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең Координацион советында тикшерелде.

2018 елда белемгә хокукларны саклау турында анализларны тикшерү берничә проблеманы күрсәтте.

Шуларның берсе мәгариф оешмасына җибәрү һәм анда урын билгеләү белән бәйле. Гражданнар Вәкаләтле вәкилгә мәктәпкәчә яшьтәге мәгариф учреждениеләренә урын алуда ярдәм итүне сорап мөрәҗәгать иттеләр. 10 нчы сыйныфларга алудан баш тарту очраклары

турында да мөрәҗәгатьләр килде. Һәм бу мөрәҗәгатьләр буенча хокук бозулар булуы ачыкланды.

Тулаем алганда соңгы елларда Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына 10 нчы сыйныфка алу буенча мөрәҗәгатьләр саны артты (2015 елда – 25, 2016 елда – 67, 2017 елда – 79). 2018 елда беркадәр кимү күзәтелде (49). Ләкин әлеге тема буенча Вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать итүчеләр артты.

Әйтик, Вәкаләтле вәкил адресына Казан шәһәренең Яңа Савин районы «Россия Герое А.В.Козин исемендәге 7-нче гимназия» гомуми белем бирү учреждениесенең 10 сыйныфына буш урыннар булмау сәбәпле кызын алмаулары, шуның белән аның белемгә хокуклары бозылу турында укучының әнисеннән мөрәҗәгать керде. Ләкин тикшерү барышында биредә ике вакантлы урын булуы ачыкланды. Вәкаләтле вәкил катнашканнан соң укучы 10 сыйныфка алынды.

Казан шәһәрендә яшәүченең Казан шәһәренең Совет районы «Советлар Союзы Герое С.Ә.Әхтәмов исемендәге 121 нче лицей»га 10 нчы сыйныфка алудан баш тарту сәбәпле улының хокуклары бозылу турында тагын бер шикаятьне тикшерү барышында шул ачыкланды, тикшерү вакытында 10 Б сыйныфында мөрәҗәгать итүченең улына тәкъдим итәргә мөмкин булган 3 буш урын бар иде.

Буш урыннар булмауга сылтау кызганычка каршы бер генә түгел. 10 нчы сыйныфка гаризалар кабул иткәндә ачыклыкны тәэмин итүче механизм юк. Мондый механизм кирәклеге зарури. Һәр үсмернең законлы вәкиле мәгариф оешмасы белән низагка керә алмый.

Узган ел бер укучының хокуклары бозылу факты киң яңгыраш алды. Берничә мәгълүмат чарасында Түбән Кама шәһәрендә укучыны бердәм дәүләт имтиханына керткәндә хокуклары бозылу, анда укучыны металл детектор аша узу өчен эчке киемен салырга мәҗбүр итүләре турында язылган иде.

Безнең тикшерү барышында шул ачыкланды, укучы кыз 5 тапкыр металл киртә аша узарга мәҗбүр булган, моңа кадәр ул тыелмаган металл предметларны (бизәнү әйберләрен) тапшырган.

Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе тәкъдим иткән мәгълүматтан күренгәнчә, укучыны озатучы укытучы әлеге предметларның укучының эчке киеменең металл

элементлары булырга мөмкинлеген әйткән. Ләкин янәшәдә торучы имтихан кабул итү пункты вәкилләре моны кире каккан.

Вәкаләтле вәкил фикеренчә, мондый укучыларның хокукларын бозу очраклары алга таба башка кабатланмаска тиеш.

Алга таба мондый хәлләр килеп чыгуны булдырмау өчен киләчәктә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына 2019 елда бердәм дәүләт имтиханнары үткәрү чорында мәгариф идарәләренә (бүлекләренә) укучы металл киртә аша узганда металл предметлар барлыгы турында хәбәр биреп, укучылар бу предметлар – кием, аяк киеме элементлары икәнен белдерә икән, имтихан алу пунктларында оештыручыларның үзләрен тоту гамәлләре турында язмача күрсәтмәләр җибәрү тәкъдим ителә.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Белем бирү өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаменты мәгълүматлары буенча 2018 елда низаглы хәлләр турында 34 мөрәҗәгать кергән. Шунысын да билгеләргә кирәк, әлеге саннар реаль хәлне объектив чагылдырмый, чөнки низаглар яшерен характерда була һәм аны еш кына хәл итеп булмастай дәрәҗәгә җиткәч кенә җиткерәләр.

Барыннан да элек, Вәкаләтле вәкилгә ата-аналардан уку процессында килеп чыккан низаглы хәлләр белән бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итәләр. Гариза бирүчеләр җитәкчеләрнең аларның педагогларның тупаслыгы, әдәпсез тәртипсезлеге турындагы мөрәҗәгатьләре буенча үзвакытында чаралар күрмәвен күрсәтәләр. Нәтиҗәдә бу низаг кискенләшеп, аны хәл итү кагыйдә буларак озакка сузыла.

Әйтик, Вәкаләтле вәкил мөрәҗәгать итүченең укучыга уку урыны бирмәүләре, педагогның үзен тупас тотуы турында белдереп уку процессын оештыруда хокук бозулар булуы турында язылган шикаяте буенча Казан шәһәре Мәскәү районы «75 нче гимназия»сендә тикшерү үткәрде. Тикшерү нәтиҗәләре буенча Казан шәһәре Мәсәкү районының «75 нче гимназиясе» директорына килеп туган хәлне җайга салу, киеренкелекне бетерү максатыннан килешү (медиация) психологик курсы мөмкинлеген файдаланып мөрәҗәгать итүчегә педагогик коллектив белән очрашулар үткәрү тәкъдиме белән чыгарга кушылды.

Әлеге мисал ата-аналарның белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучылар арасында бәхәсләрне көйләү буенча комиссиягә мөрәҗәгать итү хокукы турында белем бирү оешмалары җитәкчеләре тарафыннан мәгълүмат алмаулары турында, шулай ук низаглы хәлләрне хәл итү буенча үзвакытында тиешле чаралар күрелмәве турында сөйли.

Үз чиратында, белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучылар арасында шәхес ара низагларны хәл итүнең өстенлекле ысулы дип медиатив практикаларны үстерүне күрәбез. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгълүматлары буенча мәктәп килештерү хезмәтләренә 2016-2017 уку елында 764 мөрәҗәгать килгән, шуларның 682 е хәл ителгән, 2017-2018 уку елында 1125 мөрәҗәгать килгән, шуларның 1094 е хәл ителгән, 2018-2019 уку елында 1170 мөрәҗәгать килгән, 1136 сы хәл ителгән. Шулай итеп, мәктәп килештерү хезмәтләренең низаглы хәлләрне хәл итүдә роле арта. Шуның белән бергә мәктәп килештерү хезмәтләре мәгариф оешмаларының өчтән берендә генә оештырылган.

Югарыда әйтелгәннәрне исәпкә алып, Вәкаләтле вәкил фикеренчә, җирле үзидарәләр органнарына республиканың муниципаль мәгариф оешмаларында мәктәп медиациясе хезмәтләрен үстерү эшен активлаштырырга кирәк.

Вәкаләтле вәкил адресына белем бирү процессында тьютор белән эшләү мәсьәләсе буенча физик мөмкинлекләре чикләнгән балаларның ата-аналарыннан мөрәҗәгатьләр керә.

Асылда мөрәҗәгать итүчеләр мәгариф оешмасының тьютор ставкасы булмауны сәбәп итеп, тьютор белән эшләүдән баш тартуы белән очраша. Алар укучыларга тьютор ярдәме күрсәтүдә «Республика психологo-медико-педагогик консультацияләр» учреждениесе тәкъдимнәрен исәпкә алып, мәгариф оешмаларына бюджетны арттыру мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына мөрәҗәгать итәргә җыена.

«Республика психолого-медико-педагогик консультацияләр» учреждениесе мәгълүматлары буенча, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы мәгариф оешмаларында балаларны укыту һәм тәрбияләү өчен тьютор хезмәте

күрсәтүгә кагылышлы кирәкле шартлар тудыру буенча тәкъдим белән заключение язылган 55 бала укый. Тьюторлар ставкалары 3 бала өчен бүленгән, калган очракларда дәүләт мәгариф оешмаларында тьюторлар вазифаларын башка вазифаи йөкләмәләре булган хезмәткәрләр башкара. Шул ук вакытта бер үк мәгариф оешмасында бер балага тьютор беркетелгән, калган балаларга карата тьюторлар вазифаларын башка вазифаи йөкләмәләре булган башка белгечләр башкара.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы позициясенә ярашлы рәвештә, балага тьюторның шәхси ярдәме таләп ителгәндә, хакимият тьютор вазифасын яки тьютор функцияләрен башкаручы хезмәткәрләрне учреждение расписаниесенә кертү-кертмәү буенча мөстәкыйль карар кабул итәргә хокуклы, биредә мәгариф учреждениесенең финанс, административ, оештыру һәм башка мөмкинлекләре белән тәэмин ителә торган үз моделе эшләнә дияргә була.

Безнеңчә, балаларның белемгә тигез хокукын тормышка ашыруда вариатив мөмкинлеген булдырмау максатыннан, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына тьютор хезмәте белән тәэмин итү зарурлыгы күрсәтелгән психолого-медико-педагогия комиссиясе заключениесенә ярашлы рәвештә, физик мөмкинлекләре чикләнгән балаларны тьютор белән тәэмин итүнең төбәк моделен эшләүне тормышка ашыру кирәк.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының югарыда күрсәтелгән проблемалар буенча Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тәкъдим иткән карарларны кабул итүе белем алуга хокукны тормышка ашыруга дәүләт гарантияләрен көчәйтергә мөмкинлек бирер дип ышанабыз.

## Инвалидлар хокукларын саклау

Татарстан Республикасында хәзерге вакытта 283 399 инвалид яши (шулардан 118 887 – III төркем инвалиды, 124 660 – II төркем инвалиды, 39 852 – I төркем инвалиды).

Вәкаләтле вәкил Аппаратына 2018 елда граждан килгән мөрәҗәгатьләрне анализлау шуны күрсәтте, аларның структурасы узган еллар белән чагыштырганда үзгәрде. 2018 елда социаль объектларга,

шул исәптән физкультура-спорт оешмалары, инженерлык һәм транспорт инфраструктурага керү мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр артты.

2018 елда федераль һәм төбәк дәрәҗәсендә дә Россия Федерациясендә инвалидларны һәм башка аз хәрәкәтләнүче төркемнәрне киртәсез тирәлек белән тәэмин итү мәсьәләләренә кагылышлы мөһим карарлар кабул ителде.

Инвалидларны өстенлекле социаль, транспорт һәм инженерлык инфраструктурасы уңайлыгы белән тәэмин итү максатыннан Россия Федерациясенең «Уңайлы тирәлек» дәүләт программасы 2025 елга кадәр озынайтылды.

Татарстан Республикасында «Уңайлы тирәлек» программасы буенча 2011 елдан 2018 елга кадәр инвалидлар өчен өстенлекле өлкәләрдә 897 объект җайлаштырылган. 2018 ел йомгаклары буенча «инвалидлар өчен өстенлекле социаль инфраструктура объектлары уңайлылыгы өлеше» индикаторы өлеше 56,4 процент тәшкил итте.

Шунысын да билгеләп үтик, Татарстан Республикасы «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында 2018 елда «Уңайлы тирәлек» төре буенча 290 мөрәҗәгать басылды, шуларның 174е инде хәл ителде.

Илдә инвалидларның физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү мәсьәләләре актуальләшә бара.

«Хезмәткә һәм оборонага әзер бул» Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы положениесенә Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2018 елның 6 мартында дөнья күргән 231 нче карары белән инвалидларның һәм физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрнең гамәлдәге тест бирү үзәкләрендә ГТО комплексы нормативларын үтәүгә кагылышлы үзгәрешләр кертелде. Бу ГТО комплексын нормативларын үтәүгә ишетү, күрү, интеллект, терәк-хәрәкәт аппараты бозылган инвалидларны җәлеп итәргә мөмкинлек бирәчәк. ГТО комплексы нормативларын үтәүгә физик культура һәм адаптив спорт белән даими шөгыльләнүче 470 мең инвалидны оештыру планлаштырыла.

Россия Федерациясе хөкүмәте карары белән 2018 елдан башлап инвалидлар һәм физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр арасында

һөнәри осталык буенча «Абилимпикс» милли чемпионатын ел саен үткәрү турында карар кабул ителде.

2018 елда Татарстан Республикасында төбәкара һәм халыкара дәрәҗәдәге берничә спорт чаралары үтте, болар коляскаларда баскетбол буенча Бөтенроссия ачык турниры; начар күрүче һәм күрмәүче велосипедчылар катнашында Казахстан Республикасы командасының этап веломарафона «Астана-Париж» веломарафоны этабы.

Законнар камилләшүгә һәм инвалидлар ихтыяҗларын исәпкә алган чаралар күрелүгә карамастан бу өлкәдә проблемалар саклана.

2016 елның 9 июлендә Россия Федерациясе хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта торак биналарын һәм гомуми милекне инвалидлар ихтыяҗларын исәпкә алып яраклаштыру чаралары турында» 649 нчы карары дөнья күрде. Анда күпфатирлы йортта торак биналарын һәм гомуми милекне инвалидлар ихтыяҗлары өчен яраклаштыру һәм аларның уңайлылыгын тәэмин итү тәртибенә кагылышлы оештыру, инженер-техник һәм башка таләпләр билгеләнгән.

Торак йортның инвалид яшәү өчен яраклы булуын тикшермәгән очракларда, Вәкаләтле вәкил Аппаратына килгән шикаятьләр һәм массакүләм мәгълүмат чараларында басылган язмалар уңаеннан безнең республиканың муниципаль районнарында күрсәтелгән норматив хокукый актны тормышка ашыру мониторингын үткәрдек.

Кайбер муниципаль районнарда (Бөгелмә, Югары Ослан, Лениногорск, Яшел Үзән, Алабуга, Азнакай, Кукмара районнарында) әлеге карарны үтәү буенча күпмедер дәрәҗәдә чаралар үткәрелгән: күпфатирлы йортта торак биналарын һәм гомуми милекне инвалидлар ихтыяҗлары өчен яраклаштыру һәм аларның уңайлылыгын тәэмин итү буенча чараларны тормышка ашыруга җирле бюджеттан акча бүленгән яисә торак йортларны тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге эшләрне алга таба җирле бюджетка кертү өчен смета төзелгән.

Калган муниципаль районнар финанслау өчен үз бюджетларында акча карамыйча, торак биналарын тикшерү өчен инвалидлардан гариза булмауга сылтый, ә бит әлеге эш гариза буенча гына үткәрелергә тиеш түгел.

Билгеле, 2016 елның 9 июлендә Россия Федерациясе хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта торак биналарын һәм гомуми милекне инвалидлар

ихтыяҗларын исәпкә алып яраклаштыру чаралары турында» 649 нчы карарын үтәү шактый акча таләп итә. Ләкин хәлне анализлау шуны күрсәтә, кайбер районнар үти яки нинди дә булса чаралар күрә, ә икенчеләре акча юклыкка сылтап, әлеге проблеманы хәл итү белән бөтенләй шөгыльләнми.

Шунысын да билгеләеп үтәргә кирәк, ноябрь аенда гомум Россия инвалидлар иҗтимагый оешмалары вәкилләренең Россия Федерациясе хөкүмәте рәисе Д.А.Медведев белән булган очрашуында да әлеге карарны үтәү проблемалары турында сөйләштеләр, аның нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнары белән бергә, инвалидлар яши торган күпфатирлы йортлардагы биналарны һәм гомуми милекне, алар ихтыяҗларын исәпкә алып яраклаштыру, шулай ук алар яшәгән торак җайлаштыру һәм яшәү өчен яраклы түгел дип билгеләнгән тәртиптә танылган очракларда, аларның җайлаштырылган торак алуга хокукларын саклау буенча федераль законнар положениеләрен һәм Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларын үтәүне анализларга кушылды.

Нәтиҗәләрне, шулай ук күрсәтелгән кимчелекләрне бетерү буенча тәкъдимнәрне Россия Федерациясе хөкүмәтенә 2019 елның 1 октябренә кадәр бирергә кушылды.

Инвалидларның спорт белән шөгыльләнүе өчен шартлар тудыру шулай ук актуаль. Спорт инвалидларны һәм физик мөмкинлекләре чикләгән затларны социаль адаптацияләүдә һәм физик тернәкләндерүдә аерым роль уйный. Татарстан Республикасында инвалидларның 14 проценты физик культура белән шөгыльләнә.

Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратына даими рәвештә инвалидлардан массакүләм физкультура дәресләрен оештыру турында мөрәҗәгатьләр керә.

2018 елда Вәкаләтле вәкил адресына Казан шәһәренең инвалидларның бер иҗтимагый оешмасы җитәкчесе инвалидлар һәм өлкән яшьтәге кешеләр өчен дәресләр оештыруны сорап мөрәҗәгать итте.

50 кешедән торган иҗтимагый оешмада өлкән кешеләр дә, инвалидлар да физкультура белән шөгыльләнә. Вәкаләтле вәкилгә физкультура өчен бина, җиһазлар булмау аркасында һәм махсус әзерлекле инструкторлар ярдәме кирәк булганлыктан мөрәҗәгать иткәннәр.

Килеп туган хәлне тикшерү һәм эшчәнлеге инвалидларны физик тернәкләндерүгә һәм социаль адаптацияләүгә юнәлтелгән оешманы яклау һәм булышлык итү максатыннан, Вәкаләтле вәкил кызыксынган ведомстволар белән эш киңәшмәләре үткәрде.

Булган очрашулар нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы Татарстан Республикасы һәр муниципаль берәмлегендә өлкән яшьтәге кешеләрнең массакүләм физик культура дәресләрен оештыру буенча җирле үзидарә органнары өчен методик кулланмалар проектын төзеде. Анда шөгыльләнүчеләрнең критерийлары, йөкләнеш күләме билгеләнгән, сәламәтләндерү юнәлешендәге комплекслы дәресләр үткәрүнең үрнәк планы эшләнгән.

Инвалидларның массакүләм физик культура дәресләрен оештыру буенча җирле үзидарәләр органнары өчен методик кулланмалар эшләү төгәлләнү алдында.

Эшләнгән методик кулланмалар һәм әлеге төр гражданнарга спорт белән шөгыльләнү өчен җиһазлары булган бина һәм махсус әзерлекле инструкторлар эшен күздә тоткан шартлар тудыру буенча эшләрне үзвакытында башлау өчен, җирле үзидарә органнарына, алдан ук инвалидларның һәм өлкән яшьтәге кешеләрнең дәресләрен оештыру мөмкинлеген карарга тәкъдим ителә.

Ел дәвамында Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратына инвалидларга социаль яклау чаралары күрсәтү мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр килә.

Быел «Инвалидларның федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасын тутырганда инвалидлык вакытын билгеләү буенча «Татарстан Республикасы медико-социаль экспертиза Баш бюросы» һәм Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы бүлегендә булган мәгълүматлар туры килмәү сәбәпле, берничә дистә кешегә инвалидлык буенча пенсия түләү туктатылу хәле игътибарны җәлеп итте. Әлеге туры килмәүләр шунлыктан килеп

чыккан: кайбер очракларда гражданнарга инвалидлык турында белешмә гомерлеккә бирелгән, шул ук вакытта тикшерү нәтиҗәләре буенча беркетмәләрдә инвалидлыкның конкрет вакыты күрсәтелгән.

Контроль уңаеннан кабат тикшерү үткәрү буенча «Медико-социаль экспертиза Баш бюросы»ның вәкаләтләренә кысылмыйча, шуны гына әйтә алабыз, инвалидлык буенча пенсия түләүне туктату инвалид контроль уңаеннан кабат тикшеренү өчен килмәве һәм моның кирәклеге турында тиешенчә хәбәрдар булган очракта гына мөмкин. Билгеле, инвалидларның федераль реестрына үзгәрешләр, безнеңчә, фактта тикшеренү нәтиҗәләре яисә кешенең кабат тикшеренүгә килмәү факты буенча гына кертелергә мөмкин.

Күрсәтелгән нәтиҗә суд практикасы белән дә раслана.

Түләүләрне туктатканлыктан соң берничә граждан судка мөрәҗәгать иткән. Гражданның пенсия түләүне туктатуы законсыз булу турындагы пенсия органына дәгъвасын судларның канәгатьләндерүе билгеле.

«Инвалидларның федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасы инвалидларга гарантияләнгән социаль яклау чараларына хокукларын тормышка ашыру өчен оештырылган. Анда мәгълүматларның юклыгы яки бозылуы инвалидка хезмәт күрсәтү мөмкин булмауга китерә. Медико-социаль экспертиза органнарының мәгълүматы инвалид турындагы белешмәләрне инвалидларның федераль реестрына кертүгә нигез булып тора. Шуңа күрә мондый очракларда, медико-социаль экспертиза органнары инвалид мәгълүматларын федераль реестрга кертү турында карар кабул иткәндә, булган суд практикасын исәпкә алып, әлеге докладта күрсәтелгән бу позицияне исәпкә алса, максатка ярашлы булыр иде.

## Миграция мөнәсәбәтләре өлкәсендә кеше хокукларын саклау

2018 елның 31 октябрендә Россия Федерациясе Президенты Владимир Путин 2019-2025 елларга яңартылган Россия Федерациясе дәүләт миграция сәясәте Концепциясен раслады.

Элегрәк миграция законнарын камилләштерүгә юнәлтелгән норматив хокукый актлар кабул ителгән иде, болар – чакыручы як сыйфатында чыгыш ясаучы затлар бурычларын билгеләүгә,

чит ил гражданнарының билгеләнгән Россиягә килү максатын һәм аларның илдә булу вакытын үтәү өчен чаралар кабул итүгә; андый чаралар кабул итмәгән өчен чакыручы як сыйфатында чыгыш ясаучы юридик һәм вазифадагы затларның административ җаваплылыгын билгеләүгә, (2018 елның 19 июлендә дөнья күргән 216-ФЗ нче, 215-ФЗ нче федераль законнары); чит ил гражданының Россия территориясендә булуына кагылышлы мәгълүматның дөреслеген арттыруга кагылышлы миграция исәбе системасын камилләштерүгә кагыла.

Тулаем алганда илнең миграция сәясәте конкрет төбәкләрнең аерым бер квалификацияле белгечләренә ихтыяҗына юнәлтелә бара.

Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2018 елның 6 декабрендә дөнья күргән 1494 нче карары белән 2019 елда Россиягә виза нигезендә килгән чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итүгә ихтыяҗ 144 583 кешене – 2018 елга билгеләнгән ихтыяҗдан 81 процентны тәшкил итә.

Чит илләрдә, Россия Федерациясенең аерым субъектларында яшәүче ватандашларны ирекле күчерүгә булышлык итүче программалар расланды, аңа Татарстан Республикасы да керде.

Татарстан Республикасында чит илләрдә яшәүче ватандашларны ирекле күчерүгә булышлык итү буенча 2017-2018 елларга программа Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 30 октябрендә 821 нче карары белән расланган. Программа мәгариф, сәламәтлек саклау, авыл хуҗалыгы, спорт, мәгълүмати-коммуникацион технологияләр өлкәләрендә шөгыльләнүче белгечләрне, шулай ук бу юнәлешләр буенча укучы студентларны өстенлекле күчерүне күз алдында тота.

Татарстан мигрантлар өчен Россиянең мавыктыргыч төбәге булып кала.

2018 елда Татарстан Республикасында 335 097 чит ил кешеләре һәм гражданлыгы булмаган зат миграция исәбенә куелды, бу узган елның шул чоры белән чагыштырганда 24 процентка күбрәк.

2018 елда вакытлыча яшәүгә рөхсәт алу турында гариза белән Татарстан Эчке эшләр министрлыгының миграция буенча территориаль бүлекчәләренә 3708 чит ил гражданы, яшәүгә рөхсәт алу турында

гаризалар белән – 3776 кеше, Россия Федерациясе гражданлыгы турында гаризалар белән – 2589 кеше мөрәҗәгать иткән.

2018 елда Казанда тиз һәм уңайлы хезмәтләр алырга мөмкинлек бирүче бердәм (күпфункцияле) миграция үзәге ачылды, аның базасында «бердәм тәрәзә» режимында медицина тикшеренүе, миграция исәбенә кую, хезмәт патентлары, иминият килешүләре төзү буенча хезмәтләр күрсәтелә.

Шуның белән бергә, Вәкаләтле вәкил адресына чит ил гражданнарыннан һәм гражданлыгы булмаган затлардан аларның Россия территориясендә хокукый статусын легальләштерүне сораган мөрәҗәгатьләр керү дәвам итә һәм Россия Федерациясе гражданлыгы алу белән бәйле берничә проблема да бар.

Россия Федерациясе территориясенә балигъ булмаган яшьтә әти-әниләре белән килгән, хәзерге вакытка кадәр шәхесләрен раслаучы документлары булмаган затларның хокукый статусын билгеләү белән бәйле проблемалы хәлләр бар.

Мәсәлән, Вәкаләтле вәкил адресына түбәндәге мөрәҗәгать килде: мөрәҗәгать итүченең ата-аналары Россия гражданлыгын ала, ә ул вакытта балигъ булмаган мөрәҗәгать итүчегә карата андый карар кабул ителмәгән (кызганычка каршы, ата-аналары аны гражданлык кабул итү турындагы гаризага язмаганнар).

Балигъ булгач мөрәҗәгать итүче үзенең Россия Федерациясе территориясендә булуын законлаштырырга омтылган, әмма аны Россия гражданы дип танудан баш тартканнар.

Һәр зат балигъ булмаган яшьтә үзенең гражданлыгын билгеләүгә йогынты ясый алмый һәм монда аның гаебе юк.

Вәкаләтле вәкил әлеге дәлилләрне Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгына җибәргән хатында китерде һәм килгән җавап хатында Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының миграция мәсьәләләре буенча Баш идарәсе кушуы буенча, Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының мөрәҗәгать итүчегә 2002 елның 31 маенда дөнья күргән 62-ФЗ нче «Россия Федерациясе гражданлыгы турында» федераль законның 4 маддәсе 7 өлешен кулланып, 1991 елның 28 ноябрендә дөнья күргән 1948 - I нче «Россия Федерациясе гражданлыгы турында» Россия Федерациясе законының

15 нче маддәсе икенче өлеше нигезендә аңа тумыштан Россия Федерациясе гражданлыгын билгеләү турында заключение чыгарылуы турында әйтелде.

Шул ук вакытта мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе паспорты бирүдән баш тарту суд тәртибендә законсыз дип табылды.

Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, Вәкаләтле вәкилнең еллык доклады кысаларында Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгына Россия Федерациясе территориясенә балигъ булмаган яшьтә даими яшәү өчен килгән затлар гаризалары буенча Россия Федерациясе гражданы паспортын бирүдән баш тарту турындагы карарларны законсыз дип тану очраклары буенча суд практикасын анализларга тәкъдим итәбез.

Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының миграция мәсьәләләре буенча идарәсенең Россия Федерациясе гражданлыгын кабул итү турында гаризаны караганда баштан ук дөрес кабул ителмәгән карары алга таба мәсьәләне карауны озакка сузуга китерде.

Вәкаләтле вәкил адресына Россия Федерациясе территориясендә 2017 елның 31 декабренә кадәр яшәүгә рөхсәте булган кеше мөрәҗәгать итте.

Вакыты чыгарга тугыз ай кала ул Россия Федерациясе гражданлыгы кабул итү турында гариза бирә. Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының 2017 елның 28 июлендә чыккан карары белән аңа Россия Федерациясе гражданлыгы бирүдән баш тарталар.

2017 елның 11 октябрендә булган суд карары белән Россия Федерациясе гражданлыгы бирү турында баш тарту карары законсыз дип танылды. Суд Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгына гражданлык кабул итү турындагы гаризаны кабат карауны йөкли. 2018 елның 26 гыйнварында Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгы гариза бирүченең яшәүгә гамәлдәге рөхсәте булмауны сәбәп итеп Россия Федерациясе гражданлыгы кабул итә алмавы турында хәбәр итте.

Шулай итеп, суд карары турында белеп, вәкаләтле орган гаризаны яшәүгә рөхсәт вакыты чыкканнан соң гына карады һәм шушы нигездә кабаттан гариза бирүченең Россия Федерациясе гражданлыгын кабул итү турындагы гаризасын караудан баш тартты.

Килеп туган катлаулы хәл уңаеннан Вәкаләтле вәкил Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына мөрәҗәгать итте, аннан гариза бирүчегә Россия Федерациясе гражданлыгы бирү турында җавап алынды.

Вәкаләтле вәкил адресына Россия Федерациясе территориясеннән административ чыгарып җибәрү турында карар кабул ителгән гражданнардан һәм гражданлыгы булмаган затлардан мөрәҗәгатьләр килү дәвам итә.

2018 елның 31 маенда Яр Чаллы шәһәрендә халыкара стандартларны саклап яңа чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны тоту үзәге (алга таба – Үзәк) ачылды. Үзәк Казаннан еракта урнашса да, Вәкаләтле вәкил хезмәткәрләренең һәм җәмәгатьчелек ярдәмчесенең консультатив ярдәм күрсәтү, кабул итү практикасы дәвам иттерелде. 2018 елда Үзәктә тотылучы 400 чит ил гражданына консультатив ярдәм күрсәтелде.

2018 елда Вәкаләтле вәкил тарафыннан (язмача килгән 103 мөрәҗәгать, турыдан туры Вәкаләтле вәкил Аппаратына консультация сорап мөрәҗәгать иткән 17 гражданны да исәпкә алып), 520 чит ил гражданына ярдәм күрсәтелде.

Тоту шартларыннан зарланучылар булмаса да, Үзәктә чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны озак тоту проблемасы саклана.

2018 ел ахырына Үзәктә чит ил дәүләтләренең консуллык учреждениеләреннән 7 гражданга карата аларның нинди дә булса дәүләт гражданлыгы булмау турында документлар алынды, шуның белән аларны Россия Федерациясе чикләреннән чыгарып җибәрү мөмкинлеге бетте. Алар озак вакыт Үзәктә тотылалар.

Хәл шуның белән дә катлаулана, гражданлыгы булмаган затларны Үзәктән азат иткәндә аларның үз статусларын легальләштерү турында документлары булмый, һәм, шуңа ярашлы рәвештә җәмгыятьтә тулы канлы тормыш белән яшәүдән (рәсми төстә эшкә урнашудан, өйләнүдән, планлы медицина ярдәме алудан, инвалидлык, пенсия рәсмиләштерүдән һәм башкалардан) мәхрүм калалар.

Шунысын да билгеләп үтү мөһим, 2018 елда Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы гражданлыгы булмаган затның шәхесен

раслаучы вакытлыча документ рәсмиләштерү буенча законпроекты әзерләгән иде, кызганычка каршы ул хәзерге вакытка кадәр кабул ителмәгән.

Шуның белән бергә, гражданлыгы булмаган затлар хокукларын бозуга кагылышлы аерым проблемаларны Вәкаләтле вәкил башкарма хакимиятнең федераль органнары һәм гражданлык җәмгыяте институтлары белән бергә хәл итте. Вәкаләтле вәкил каршындагы Эксперт советы үткәрү нәтиҗәләре буенча гамәлгә кергән суд карарларын Үзәккә илтү вакыты тизләтелде, бу чит ил гражданнарын Үзәктә озак вакыт тотмаска мөмкинлек бирә.

2019 елда «Яңа гасыр» автоном хәйрия коммерциячел булмаган оешмасы белән берлектә мигрантларны хокукый агарту буенча чараларны алга таба да үткәрү планлаштырыла. «Казан (Идел буе) федераль университеты» юридик факультетының халыкара хокук һәм интеграция проблемалары, кеше хокуклары фәнни-мәгариф үзәге белән берлектә, Россия Федерациясе чикләреннән административ чыгарып җибәрү рәвешендә административ җәза билгеләү турында карар кабул ителгән чит ил гражданнарына карата, аларның хокукларын саклау буенча проблемалар анализланачак.

## Пенитенциар система учреждениеләрендә тотылучы затлар хокукларын саклау

Теләсә кайсы дәүләттә гражданнарның аерым бер өлеше җинаятьләр кыла һәм соңыннан махсуслашкан учреждениеләрдә җәза үтү юлы белән җаваплылык тоя. Шул ук вакытта беркадәр чикләүләр белән булса да, мәҗбүри тоту урыннарында тотылучылар теләсә кайсы кеше өчен аерылгысыз булган хокукларга ия.

Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе учреждениеләрендә 2019 елның 1 гыйнварына 10424 кеше тотылган (узган елның шул чорында – 11200 кеше), шулардан 8505 кеше – төзәтү учреждениеләрендә (узган елның шул чорында – 9035 кеше), 1919 кеше – тикшерү изоляторларында. (узган елның шул чорында – 2165 кеше). 2018 елда иректән мәхрүм итү урыннарыннан 4419 кеше азат ителгән (узган елның шул чорында – 4392 кеше).

Татарстан Республикасы шәһәр округлары һәм муниципаль районнары буенча Россия Эчке Эшләр министрлыгы бүлекләре һәм бүлекчәләре дежур частьларының тоткарланган затларны тоту өчен махсус бүлмәләре, вакытлыча тоту изоляторлары аша 2018 елда 92 меңнән артык кеше узган.

Мәҗбүри тоту урыннарында контрольне тормышка ашыручы субъектларның берсе буларак Вәкаләтле вәкил, 2018 елда мәҗбүри тоту урыннарында тотылучы гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен саклауны тәэмин итү буенча максатчан эш алып барды.

Вәкаләтле вәкил адресына килгән мөрәҗәгатьләрне караудан тыш, республиканың төзәтү учреждениеләрендә 265 кешене эченә алган 11 «Хокукый ярдәм көне» үткәрелде. Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгы белән бергәләп ел дәвамында 20 муниципаль районнардагы һәм шәһәр округларындагы вакытлыча тоту изоляторлары һәм махсус тоту бүлмәләре тикшерелде.

2018 елда Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе төзәтү учреждениеләрендә чаралар куллану, хөкем ителгәннәрне җәза үтәтүдә вакытыннан алда шартлы рәвештә азат итү турында юлламалар, үтелеп бетмәгән җәзаны җиңелрәк җәза төренә алыштыру, төзәтү учреждениесе төрен үзгәртү мәсьәләләре буенча Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе төзәтү учреждениеләрендәге комиссияләр эшендә Вәкаләтле вәкил хезмәткәрләре катнашу практикасы яңартылды.

Шунысын да билгеләргә кирәк, махсус контингентны эчке эшләр органнарының мәҗбүри тоту урыннарында тоту шартлары яхшырды. Мәсәлән, соңгы берничә елда эчке эшләр органнарының биш территориаль бүлекләрендә (Әгерҗе, Азнакай, Актаныш, Әлмәт һәм Балтач муниципаль районнарында) яңа вакытлыча тоту изоляторлары биналары һәм махсус тоту урыннары сафка бастырылды, шулай ук 15 бүлекчәдә махсус учреждениеләргә капиталь ремонт ясалды.

2018 елда Лаеш районы буенча эчке эшләр бүлегендә вакытлыча тоту изоляторына һәм махсус тоту урынына реконструкция үткәрелде, Сарман районы буенча эчке эшләр бүлегендә эшләр алып барыла,

шулай ук Казан эчке эшләр идарәсе махсус тоту бүлмәсенә, Мамадыш районындагы вакытлыча тоту изоляторына капиталь ремонт үткәрелде. Бөгелмә районы эчке эшләр бүлеге буенча полиция махсус учреждениеләрен ремонтлау буенча эшләр төгәлләнеп килә.

2019 елда Алексеевский, Чүпрәле, Питрәч районнары буенча эчке эшләр бүлекләре, Югары Ослан районара бүлегендә вакытлыча тоту изоляторларына һәм махсус тоту урыннарына капиталь ремонт үткәрү планлаштырылган.

«2014-2021 елларга Татарстан Республикасында җәмәгатьчелек тәртибен һәм җинаятьчелеккә каршы гамәлләрне тәэмин итү» дәүләт программасы кысаларында Норлат районы буенча эчке эшләр бүлегендә вакытлыча тоту изоляторын һәм махсус тоту урынын капиталь төзекләндерү каралган. Аксубай һәм Чистай районнары буенча эчке эшләр бүлекләрендәге вакытлыча тоту изоляторларын 2020 елда төзекләндерү планлаштырылган.

Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе ведомствосындагы учреждениеләрдә дә махсус контингентны тотуга уңайлы шартлар тудыру буенча эш күренә.

Инвалидлыгы булган, иректән мәхрүм ителгән һәм тоткынлыкта булган хөкем ителүчеләрнең гарантияләнгән хокукларын тәэмин итү максатларында (2018 елның 1 декабренә Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе учреждениеләрендә 283 инвалид исәптә торган: I төркем – 7 кеше; II төркем – 146 кеше; III төркем – 130 кеше), Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе учреждениеләрендә инвалидлар өчен тоткарлыксыз тирәлек булдыру, объектларны уңайлы итү буенча эш алып барыла.

2018 елда Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе учреждениеләрендә 20 керү пандуслары куелган, 20 санитар узел җиһазландырылган, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсенең 17 нче-КП, 10 нчы төзәтү колонияләре тулай торакларына комплекслы ремонт ясалганда тоткарлыксыз тирәлек оештыруга игътибар бирелә.

2018 елда шулай ук барлык хөкем ителүчеләргә социаль пособиеләр, шулай ук айлык түләүләр алуга документлар тутырылды, 1788 медицина полисы һәм 1692 СНИЛС ясатылды.

Төзәтү учреждениеләреннән азат ителүгә, иректәге тормышка әзерләнүче тоткыннар белән аерым эш оештырылган. Әйтик, 2 нче төзәтү колониясендә, 19 нчы төзәтү колониясендә эксперимент рәвешендә 2018 елда махсус адаптация отрядлары оештырылды, аларда тоткыннарны төзәтү учреждениеләреннән азат ителгәч алга таба иректә яшәү өчен әзерлиләр.

Матди-көнкүреш шартлары ягыннан мәҗбүри тоту урыннарында тоту шартлары яхшыга таба үзгәрүгә карамастан, Вәкаләтле вәкилгә узган еллардагы кебек үк мәҗбүри тоту урыннарында тотылучы затлардан медицина ярдәме күрсәтү белән бәйле, әйтик, тиешенчә медицина ярдәме күрсәтелмәү, булган авырулар буенча дару препаратлары белән тәэмин итүгә кагылышлы берничә дистә шикаять килде.

Доклад чикләрендә түбәндәгеләргә тукталу максатка ярашлы дип уйлыйм.

Тулаем алганда Россия Җәзаларны үтәтү хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән бергә, шикләнелүчеләрне, гаепләнүчеләрне һәм хөкем ителгәннәрне медицина ярдәмен пенитенциар системада күрсәтергә мөмкин булмаганда медицина ярдәме күрсәтү өчен сәламәтлек саклау дәүләт һәм муниципаль учреждениеләренә җибәрү эшен оештырган.

Әйтик, 2018 елда Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең «16 нчы медико-санитар часте»нең хастаханәсе филиалыннан медицина оешмаларына 54 авыруны озатканнар, үзләрендә тар белгечләр 449 консультация, 11 тикшерү уздырган.

Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең «16 нчы медико-санитар часте» учреждениесен белгечләр җәлеп итеп тикшерү барышында шикаятьләрдәге дөрес дәваламау турындагы зарлар расланмады.

Шуның белән бергә, республиканың прокуратура органнары кайбер төзәтү учреждениеләрендә (Россия Җәзаларны үтәтү федераль

хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе 4 нче төзәтү колониясендә һәм 10 нчы төзәтү колониясендә) медицина ярдәме махсус контингентка карата тиешенче күрсәтелмәгән аерым очракларны ачыклады, әйтик, тоткынга алга таба дәвалау мәсьәләсен хәл итү өчен тар белгеч белән кирәкле консультация оештырылмаган, төзәтү учреждениесенең медицина частендә сулыш системасы һәм тән тиресе авыруларын дәвалау өчен кирәкле дару препаратлары булмаган.

Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе учреждениеләрендә үлүчеләр саны кимүгә карамастан, 2018 елда 45 кеше вафат булды (узган елның шул чорына - 60 кеше), Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе учреждениеләрендә асылынып үлүчеләр саны борчу уята, узган ел 10 шундый факт булды, 2017 елда да шулай ук иде.

Моннан тыш, 2018 елда Вәкаләтле вәкилгә вакытлыча тоту изоляторларында тотылучыларны сәламәтлек саклау учреждениеләренә җибәрергә кирәк булса да, моннан баш тарту очраклары күп булу турында мәгълүмат килде.

Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе һәм Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең «16 нчы медико-санитар часте» мәгълүматлары буенча Россия Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы шәһәр округларындагы һәм мунипаль районнардагы бүлекләре һәм бүлекчәләрендәге вакытлыча тоту изоляторларыннан 2018 ел дәвамында медицина күрсәткечләре буенча тикшерүдәге-кулга алынган затларны кабул итү буенча 51 кире кагу теркәлгән. Тикшерүдәге-кулга алынган затларны тикшерү изоляторларына алмау сәбәбе итеп, төрле дәрәҗәдәге имгәнүләр, термик пешүләр, ялкынсыну процесслары, югары температура булу, соматик авырулар аркасында йөклелек катлаулану, кискен формадагы катлаулыклар белән йогышлы авырулар кискенләшү күрсәтелә.

Һичшиксез, Россия Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы шәһәр округлары һәм муниципаль районнарындагы бүлекләре һәм бүлекчәләренең вакытлыча тоту изоляторлары хезмәткәрләре (кизү торучылар) медицина ярдәме күрсәтү

күнекмәләренә ия булырга тиеш. Бу уңайдан Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, вакытлыча тоту изоляторларындагы хезмәткәрләрне (кизү торучыларны) алга таба тиешле таныклык биреп, медицина ярдәме күрсәтү нигезләренә өйрәтү турында килешү төзү максатка ярашлы булыр иде.

Татарстан Республикасының Питрәч, Балык Бистәсе, Әлки, Алексеевский, Спасс, Лаеш муниципаль районнарындагы вакытлыча тоту изоляторларында үткәрелгән тикшерүләр йомгаклары буенча шул ачыкланды, махсус контингент вакытлыча тоту изоляторыннан киткәндә медицина тикшеренүе журналларына медицина хезмәткәре карады дигән билге куелмаган.

Шушы уңайдан Татарстан Эчке эшләр министрлыгына Россия Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы шәһәр округларындагы һәм муниципаль районнарындагы бүлекләре, бүлекчәләре җитәкчеләренә вакытлыча тоту изоляторыннан азат ителгән яки этапка озату өчен конвойга тапшырылган затларны сәламәтлеге торышын, тәнендәге яраларын карап, тикшеренүне медицина журналларында чагылдырган медицина тикшеренүләре үткәрү буенча чаралар оештыруны тәкъдим итәм.

Агымдагы елда Вәкаләтле вәкил адресына сак астында тотылган хатын-кызлардан 1995 елның 15 июлендә дөнья күргән 103-ФЗ нче «Җинаятьләр кылуда шикләнелүче һәм гаепләнүчеләрне сак астында тоту турында»гы федераль законның 30 нчы маддәсенә ярашлы рәвештә, тикшерү изоляторы шартларында үзенең 3 яшькәчә баласы белән булу мөмкинлеге бирү турында мөрәҗәгатьләр килә башлады.

Әйтик, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе 4 нче тикшерү изоляторында тотылучы хатын-кызга сак астында үзенең баласы белән бергә булуын сораган гражданнан мөрәҗәгать керде.

Хәл мондый. Җинаять кылуда гаепләнүче хатын-кыз баласы туугa ук тикшерү изоляторына эләккән. Бала медицина күрсәткечләре буенча сәламәтлек саклау учреждениесендә калдырылган. Соңрак хатын-кыз сак астында баласы белән бергә булырга теләк белдергән. Ләкин Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының опека

һәм попечительлек бүлеге әлеге хатын-кызның баласын тулысынча дәүләт тәэминатында булган дәүләт учреждениесенә урнаштыру турында карар кабул иткән. Шул ук бу күрсәтелгән карар әлеге хатын-кызның тикшерү изоляторында булуыннан чыгып кына кабул ителгән.

Билгеле, хәлләр төрле булырга мөмкин. Әгәр баланың аны үзләренә алып соңрак аңа опека рәсмиләштерә ала торган якын туганнары бар икән, алар белән булу балага уңайлырак булырга мөмкин (билгеле хатын-кызның баласы белән бергә булу хокукы бар, бу очракта тикшерү изоляторы хакимияте баласы белән булучы анага тиешле шартлар тудырырга тиеш). Якын туганнары булмаганда икенче мәсьәлә, ул вакытта бала анасы аннан баш тартмаса да, тугач ук «социаль ятим»гә әйләнә.

Бу уңайдан Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе җирле үзидарә органнары белән өч яшькәчә баласы булган тикшерү изоляторларында тотылучы хатын-кызларның теләге булса, мәҗбүри тоту урыннарында баласы белән бергә булуга хокукларын тормышка ашыру буенча проблемалы мәсьәләләрен бергәләп карарга тиеш дип саныйбыз.

Мөрәҗәгатьләрнең күбесе җәза үтәүдән вакытыннан алда азат итүгә кагыла.

2018 елда Вәкаләтле вәкил адресына Россия Федерациясе Җинаять кодексының 72 нче маддәсенә - иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза вакыты суд карары буенча законлы көченә кергәнчегә кадәр сак астында тотылучы затның тотылу вакытын яңача исәпли торган үзгәрешләр кертелү уңаеннан мөрәҗәгатьләр килде.

Әлеге үзгәрешләр уңаеннан Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе төзәтү учреждениеләрендә әлеге законга эләгүче хөкем ителүчеләргә карата материалларын судка җибәрү буенча эшне оештырды.

2018 елның 3 июлендә кабул ителгән 186-ФЗ нче «Россия Федерациясе Җинаять кодексының 72 маддәсенә үзгәрешләр кертү турында» федераль закон кабул ителү белән бәйле җәза вакытларын кабат исәпләү 1434 хөкем ителүчегә кагылды.

Каты авыру аркасында хөкем ителүчеләрне җәза үтәүдән азат итү проблемасы кабаттан борчу тудыра.

Әлеге проблема узган еллардагы докладларда да чагылыш тапкан иде.

Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе мәгълүматлары буенча 2018 елда андый очраклар арткан. Каты авыру аркасында аларны азат итү турында материаллар җибәрелгән 45 тоткынның суд карар чыгарганчы 13е вафат булган (2017 елда андыйларның саны – 8 булган).

Күп очракта каты авыру аркасында хөкем ителүчене азат итү турында судларга җибәрелгән материаллар нигезле булган (28 хөкем ителүче азат ителгән, 4 тоткынга аларның юлламасын канәгатьләндерүдә кире какканнар).

Китерелгән мәгълүматларны исәпкә алып, әлеге доклад кысаларында Татарстан Республикасы Югары Судына, каты авыру сәбәпле җәза үтәүдән азат итү мәсьәләләре буенча суд практикасын берләштерү һәм күзәтү әзерләү мәсьәләсен карауны тәкъдим итү максатка ярашлы булыр иде.

Әлеге тема буенча мөрәҗәгатьләрнең артуы җәза үтәүдән вакытыннан алда шартлы рәвештә азат ителү мәсьәләләре белән дә бәйле. Судка төзәтү учреждениеләренең материалларны төзәтү учреждениеләре хакимиятләренең тискәре характеристикалары белән җибәрелүе игътибарны җәлеп итә.

Мәсәлән, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсенең 10 нчы төзәтү колониясендә тотылучы хөкем ителүчегә тискәре характеристика әзерләнгән, аерым алганда, хөкем ителүченең нинди дә булса дингә мөнәсәбәте билгесез булуы әйтелгән, шул исәптән, Россия Федерациясе Конституциясеннән мәгълүм булганча, дин тоту ирекле, кешенең атеист булырга да хакы бар.

Билгеле, төзәтү учреждениеләренең позициясе хөкем ителүчеләрнең гаризаларын караучы судлар позицияләре белән туры килмәскә дә мөмкин. Шуның белән бергә, төзәтү учреждениесе хакимияте характеристикасы судья өйрәнә торган материалларның берсе.

Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсенең 2018 елның 5 декабренә булган мәгълүматларына ярашлы рәвештә, 2018 елда судлар, төзәтү

учреждениесенең тискәре характеристикасы булган хөкем ителүчеләрнең җәза үтәүдән вакытыннан алда шартлы рәвештә азат итү турындагы 392 юлламасын караган, шулардан судлар 4 сен генә канәгатьләндергән. Шулай итеп, судлар мондый юлламаларны караганда, судларның позициясе күп очракта төзәтү учреждениесе хакимияте фикере белән туры килә.

Әлеге уңайдан Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе төзәтү учреждениеләре җитәкчеләре белән хөкем ителүчеләргә характерлаучы документлар әзерләгәндә, һәр затны өйрәнгәндә игътибарлырак һәм объектив булу мәсьәләсен караса, шулай ук вакытыннан алда шартлы рәвештә азат ителүгә судка юлламалар бирүче, хөкем ителүчеләргә хөкем ителүчегә бәйле булмаган сәбәпләр буенча тискәре характеристика язмау мәсьәләсен караса, максатка ярашлы булыр иде.

Иректән мәхрүм итү урыннарда булган затлардан җинаять суд производстволары һәм алга таба җәза үтәүдән азат итү белән бәйле мәсьәләләрдән тыш, җәза үтәгәннән соң көнкүрешен җайлау белән бәйле мөрәҗәгатьләр дә керә. Алар арасында ятим балалар, ата-анасыннан калган балалардан азат ителгәннән соң аларны торак белән тәэмин итүгә, аларны билгеләнгән тәртиптә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар дип тану сораган мөрәҗәгатьләр килә.

Төзәтү учреждениесендә булган, торакка мохтаҗ затларга җәза вакыты тәмамлангач торак бирелмәү мөмкинлеге турындагы хәлләр безнең практикада юк. Суд карары билгеләнгән җәза вакыты чыккач андый затларга торак бирү, вәкиллекле орган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан гарантияләнә. Шуның белән бергә андый зат вакытыннан алда азат ителгән очракта үзвакытында торак белән тәэмин ителәме, аңлашылмый.

Әйтик, Вәкаләтле вәкилгә Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе 19 нчы төзәтү колониясендә тотылучы тоткын мөрәҗәгать итте, аңа Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы җәзаны үтәп кайтканнан соң найм килешү шартларында махсуслашкан торак фондыннан торак белән тәэмин ителәчәк дигән җавап биргән. Әлеге тоткын вакытыннан алда иреккә чыккан очракта, ятим бала һәм ата-анасыз калган балалар

исәбеннән үзвакытында махсуслашкан торак фондыннан торак белән тәэмин ителәчәкме, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы җавабында бу әйтелмәгән.

Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсенә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән бергә, ятим балалар исәбеннән булган (билгеләнгән тәртиптә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип танылган) суд хөкеме буенча irектән мәхрүм итү урыннарыннан вакытыннан алда чыккан очракта, мондый гражданнарга махсуслашкан фондтан үзвакытында торак бирү мәсьәләләрен карау максатка ярашлы булыр дип саныйбыз.

Үз эшчәнлеге кысаларында Вәкаләтле вәкил социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар белән даими хезмәттәшлектә тора.

2018 елда Вәкаләтле вәкил башлангычы белән кызыксынган министрлыклар, ведомстволар һәм социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар катнашында Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе 19 нчы төзәтү колониясе базасында наркотик һәм психоактив матдәләрдән бәйле хөкем ителүчеләрне тернәкләндерүгә, аларны төзәтү учреждениесеннән азат ителгәч яшәячәк тормышка әзерләүгә юнәлтелгән проектны тормышка ашыру буенча эш башкарылды.

«Мохтаҗларга бушлай ярдәм» социаль проекты кысаларында «Социаль тернәкләндерү һәм адаптацияләү үзәге» оешмасы Вәкаләтле вәкил һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый оешмасы белән бергә авыр хәлдә калган кешеләргә ярдәм итә торган бушлай юридик ярдәм күрсәтү проектын эшләтеп җибәрде.

Шулай ук Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе төзәтү учреждениеләренә гуманитар ярдәм күрсәтүгә юнәлтелгән хәйрия акцияләре дә үткәрелә.

Мәҗбүри тоту урыннарында кеше хокукларын саклау элеккечә үк Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты контролендә кала.

# Йомгак

Докладта бәян ителгән кеше хокукларын тәэмин итү һәм яклау проблемаларыннан чыгып, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил түбәндәге нәтиҗәләргә туктала.

Хезмәт хокукый мөнәсәбәтләрендә элеккечә үк эш хакын вакытында түләмәү кискен тора. Хезмәткәрләрнең эш хакын вакытында һәм тулысынча алуга хезмәт хокукларын яклауга гарантияләрне көчәйтү буенча системалы эш, аерым бер предприятиеләрнең озак вакыт эш хакы түләмәве фактларына тиз арада нәтиҗәле чаралар күрүне исәпкә алып дәвам иттелергә тиеш.

Республикада эш эзләүдә авырлыклар кичергән гражданнарга эш табуга булышлык итүче чаралар планлы рәвештә алып барыла. Үз чиратында, картлык буенча иминият пенсиясенә чыгу өчен пенсия яшен арттыру уңаеннан, дәүләт органнарыннан пенсия алды яшендәге кешеләрне эшкә алганда дискриминацияне кисәтү өчен эшлекле чаралар кабул итү йөзеннән, пенсия алды яшендәге затларның хезмәткә хокукларын яклау буенча актив эш таләп ителә.

Татарстанда производствода бәхетсезлек очракларын киметү буенча системалы эш алып барыла. Шуның белән бергә, Татарстан Республикасының кайбер муниципаль районнарында җирле үзидарә органнарына алар буйсынуындагы ведомстволар учреждениеләрендә хезмәтне саклау өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне саклауга ныклы игътибар бирергә кирәк.

Торак мөнәсәбәтләре өлкәсендә «аварияле торак» проблемаларын хәл итү белән бәйле кискен мәсьәләләр кала. Билгеләнгән тәртиптә аварияле дип танылган һәм сүтелергә тиешле яисә алардан файдалану барышында, нык тузуы аркасында төзекләндерелергә тиешле күпфатирлы йортлардан гражданнарны күчерү буенча чаралар торак бинасын, күпфатирлы йортны яшәү өчен яраксыз, аварияле дип тану буенча ведомствоара комиссияләрнең эше, гамәлдәге законнарда билгеләнгән барлык мәҗбүри таләпләрне саклап алып барылырга тиеш.

Транспорт чараларының интенсив хәрәкәте уңаеннан (тавышның тиешледән артып китүе сәбәпле), торак биналарда яшәүгә уңайлы шартларга хокуклары бозылу турында очраклар, мондый йортлары

булган җирле үзидарә органнарының күрсәтелгән кимчелекләрне бетерү буенча тиешле чаралар күрмәве игътибарны җәлеп итә.

Гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендә элеккечә үк табибка электрон яки башкача рәвештә язылу, медицина ярдәме күрсәтүне көтү вакытына кагылышлы проблемалар кала.

Бушлай белем алуга хокук өлкәсендә хәзерге вакытка кадәр 10 нчы сыйныфка алганда нигезсез баш тартулар бар, һәм бу проблема ахыргача хәл ителеп бетмәгән. Мәгариф мөнәсәбәтләрендә катнашучылар арасында шәхес ара низагларны хәл итүнең өстенлекле ысулы буларак медиатив практикалар кертү буенча эшне камилләштерү таләп ителә. Физик мөмкинлекләре чикләнгән балаларны укытуны оештыруның аерым мәсьәләләре буенча нәтиҗәле идарә карарлары кирәк.

Нәтиҗәле социаль сәясәт инвалидларга социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралар объектларына тоткарлыксыз үтеп керүне тәэмин итүдән башка мөмкин түгел. Республиканың һәр муниципаль берәмлегендә 2016 елның 9 июлендә Россия Федерациясе хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта торак биналарын һәм гомуми милекне инвалидлар ихтыяҗларын исәпкә алып яраклаштыру чаралары турында» 649 нчы карарын үтәүгә керешергә кирәк. Инвалидларның массакүләм физик культура дәресләре өчен уңайлы шартлар тудыру буенча эшне дә камилләштерү таләп ителә.

Татарстан элеккечә үк мигрантлар өчен мавыктыргыч төбәк булып кала. Бу уңайдан чит ил гражданнары тарафыннан Россия Федерациясе территориясендә законлы яшәүгә рөхсәт бирү статусы белән бәйле мәсьәләләр шактый әһәмияткә ия.

Мәҗбүри тоту урыннарында сәламәтлек саклауга һәм медицина ярдәменә хокукларны тормышка ашыру, хатын-кызларны сак астында тоту үзенчәлеклре белән бәйле проблемалар бар. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлар хокукларын тормышка ашыру мәсьәләләре дә актуаль булып кала.

Югарыда әйтелгәннәрне исәпкә алып, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тәэмин итү һәм көчәйтү максатларында Вәкаләтле вәкил дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм вазифадагы затларга түбәндәге чараларны күрергә тәкъдим итә.

1. Хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә кеше хокукларын тормышка ашыру максатларында:

1.1. Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгына яшь буенча эшкә алганда дискриминацияне кисәтүгә юнәлтелгән өстәмә чаралар күрергә.

1.2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетына, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы башкарма комитетына алар карамагындагы ведомстволар учреждениеләрендә производствода бәхетсезлек очраклары профилактикасына юнәлтелгән чаралар күрергә.

2. Гражданнарның торакка хокукларын тормышка ашыру максатларында:

2.1. Җирле үзидарә органнарына торак биналарын бәяләү һәм тикшерү буенча ведомствоара комиссияләр эшен тормышка ашырганда, һәр очракта Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварында дөнья күргән 47 нче карары белән расланган (торак биналар милекчеләренең ведомствоара комиссиясе утырышларында билгеләнгән тәртиптә катнашуы, комиссия составы буенча таләпләрне үтәү) торак йортны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны аварияле һәм сүтү яки төзекләндерү тиешле дип тану турында Положениенең 7 пункты таләпләрен исәпкә алырга.

2.2. Казан шәһәре башкарма комитетына һәм Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетына Казан шәһәренең Җиңү проспекты һәм Энергетиклар урамнарында, Әлмәт шәһәренең Колхоз урамында урнашкан йортлар буенча транспорт хәрәкәте тавышы дәрәҗәсен киметүгә юнәлтелгән чаралар күрергә.

3. Гражданнарның сәламәтлек саклауга һәм медицина ярдәменә хокукларын тормышка ашыру максатларында:

3.1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына

табибка кабул итүгә электрон рәвештә язылу уңайлыгын күтәрүгә юнәлтелгән тәкъдимнәр эшләргә;

Медицина учреждениеләренең профилактик прививка чараларын оештыруга контрольне көчәйтергә.

4. Гражданнарның бушлай белем алуга хокукларын тормышка ашыру максатларында:

4.1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

укучыларны мәгариф оешмасына 10 нчы сыйныфка алуны ачыклык принципларына нигезләп оештыруга юнәлтелгән өстәмә чаралар кабул итү турында мәсьәләне карарга;

Физик мөмкинлекләре чикләнгән балаларга, әгәр тьютор хезмәте кирәклеге психолого-медико-педагогик комиссия заключениесендә тәкъдим ителгән булса, төбәк моделе буенча тьютор билгеләүне тәкъдим итәргә.

4.2. Җирле үзидарә органнарына муниципаль мәгариф оешмаларында мәктәп медиациясе хезмәте оештыру аша медиатив практикалар кертү буенча чараларны активлаштырырга.

5. Инвалидларның хокукларын тәэмин итү һәм яклау максатларында:

5.1. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына җирле үзидарә органнары белән бергә, спорт белән шөгыльләнү биналарына, спорт җиһазларына һәм халыкның әлеге төркеме вәкилләре белән дәресләр алып бару буенча махсус әзерлек узган инструкторларга булган ихтыяҗны исәпкә алып, инвалидларның һәм өлкән яшьтәге кешеләрнең физик культура дәресләре эшен оештыру буенча эшне дәвам итәргә.

5.2. Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына 2016 елның 9 июлендә Россия Федерациясе хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта торак биналарын һәм гомуми милекне инвалидлар ихтыяҗларын исәпкә алып яраклаштыру чаралары турында» 649 нчы карарына ярашлы рәвештә, инвалидларны социаль яклауга юнәлтелгән мәҗбүри чаралар исемлеген тормышка ашыру буенча чаралар күрергә.

6. Гражданнарның миграция мөнәсәбәтләре өлкәсендә хокукларын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгына, Россия Федерациясе территориясенә даими рәвештә яшәү өчен балигъ булмаган яшьтә килгән затлар гаризасы буенча Россия Федерациясе гражданы паспорты бирүдән баш тарту турында карарларны законсыз дип тану очраклары буенча суд практикасын анализларга.

7. Мәҗбүри тоту урыннарында тотылучы затларның хокукларын саклау максатларында:

7.1. Татарстан Республикасы Югары судына каты авыру аркасында җәза үтәтүдән азат итү мәсьәләләре буенча күзәтү әзерләү һәм суд практикасын берләштерү мөмкинлеге турындагы мәсьәләне карарга.

7.2. Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгына:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән берлектә вакытлыча тоту изоляторларында эшләүче хезмәткәрләрне (кизү торучыларны) медицина ярдәме күрсәтү нигезләренә өйрәтүгә юнәлтелгән чаралар күрергә;

Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының шәһәр округлары һәм муниципаль районнардагы бүлекләре җитәкчеләренә вакытлыча тоту изоляторларыннан азат ителгән яисә этап белән озату өчен конвойга тапшырыла торган затларның сәламәтлеге торышы турындагы мәгълүматны медицина журналларына теркәп, медицина тикшеренүләре үткәрү буенча чаралар оештырырга.

7.3. Россия Федерациясе Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсенә:

җирле үзидарә органнары белән берлектә тикшерү изоляторларында тотылучы һәм өч яшькәчә баласы булган хатын-кызларның теләге булган очракта, аларны мәҗбүри тоту урыннарында баласы белән бергә тотуга хокукларын тормышка ашыру буенча проблемалы мәсьәләләрне карарга;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә иректән мәхрүм итү урыннарында җәза үтүче, билгеләнгән тәртиптә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип табылган ятим балаларга, суд карары буенча билгеләнгән вакыттан алда азат ителгән очракта, махсуслашкан фондтан үзвакытында торак бирү белән бәйле мәсьәләләрне карарга.

Татарстан Республикасында Кеше
хокуклары буенча вәкаләтле вәкил,
С.Х. Сабурская

Казан, февраль, 2019 ел